وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!

6+

ДИН вә МӘГЫЙШӘТ

№15-16 (210-211). 1 ноябрь 2013 / 27-зөлхиҗҗә-1434

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ

# ИМИН ЕЛЛАР БУЛСЫН!

**Бисмилләһир-рахмәнир-рахим! Әссәләәмү галәйкүм үә рахмәтүллаһи вә бәракәәтүһ!**



Мөхтәрәм җәмәгать! 4 нче ноябрьдә һиҗри буенча яңа ел башлана. Аллага шөкер, күңелләребез белән Раббыбызга сыенып, догалар кылып 1435 нче һиҗри елга аяк басабыз. Ел иң күркәм айлардан саналган мөхәррәм ае белән башланып китә.

Мәгълүм булганча, Мәккә шәһәрендә динне тоту кыенлашканнан соң сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вәссәлам һәм аның сәхабәләре Мәдинә шәһәренә күченә. Бу күчеш, ягъни гарәпчә әйткәндә һиҗра, бөтен дөнья тарихына зур үзгәрешләр керткән вакыйга. Менә шул күчештән башлап, Мәдинәдә беренче хакыйкый ислам җәмгыяте төзелә. Мәдинәдән ислам, иман һәм Коръән нуры, әдәп-әхлак, тән һәм җан пакьлеге бөтен дөньяга тарала.

Мөселманнар еллар хисабын да Мөхәммәд Пәйгамбәрнең (с. г. в.) Мәккәдән Мәдинәгә күчкән вакыттан саный башларга килешә. Һиҗри ел исәбе ай торышына карап алып барыла.

4 нче ноябрь мөхәррәмнең тәүге көне. Мөхәррәм ае ызгыш-талашлар, низаглар тыелган дүрт айның (рәҗәп, зөлкагдә, зөлхиҗҗә, мөхәррәм) берсе. Бу айда кылынган гамәл-гыйбадәтләребезнең, игелекле эшләребезнең әҗер-савабын Аллаһы Тәгалә бик күп мәртәбәләргә арттыра, иншә Аллаһ. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с. г. в.) үзенең бер хәдисендә: "Рамазан уразасыннан соң иң фазыйләтле ураза - мөхәррәм аенда тотылган уразадыр", - ди. Икенче бер хәдисендә исә болай диелә: "Мөхәррәм аенда бер көн ураза тоткан кешегә 30 көн ураза тоткан кадәр савап языла".

Раббыбыз илебезгә иминлек-тынычлык биреп, тормышларыбызны бәрәкәтле итсә иде. Һәркайсыбызга елларыбызны иманлы булып үткәрергә, гаиләләребез, якыннарыбыз бәхетен күреп яшәргә язсын.

***Мөфти Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН,***
***Үзкләшкән дини оешма - Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте рәисе***

# МӨХӘРРӘМ АЕ ҺӘМ ҺИҖРИ ЯҢА ЕЛ ҖИТӘ

**Бөтен галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһы Сөбханәһү вә Тәгаләгә иксез-чиксез хәмде-сәналәребез (мактауларыбыз), шөкраналарыбыз булса иде. Аның сөекле илчесе газиз Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вәссәламгә, аның гаиләсенә, барлык сәхабәләренә сәламнәребез һәм салаватларыбыз булса иде.**

Без 4 нче ноябрьдә яңа айга, ягъни мөхәррәм аена гына түгел, яңа 1435 нче һиҗри елга да аяк басабыз.

Аллаһы Тәгалә Коръәни-Кәримдә болай дип әйтә:

وَمَن يُعَظِّمْ شَعَائِرَ اللَّهِ فَإِنَّهَا مِن تَقْوَى الْقُلُوبِ

Мәгънәсе: *"Шөбһә юктыр, Аллаһы Тәгаләнең шигарьләрен (хөкемнәрен) хөрмәт иткән кешенең күңеле тәкъвалыктадыр"*.

Чыннан да, һиҗри ел башы Раббыбызның иң олы булган шигарьләренең берсе. Әгәр без тәкъвалардан булырга теләсәк, аны олыларга тиешбез. Әмма аның серләрен, хикмәтләрен, хасиятләрен белмичә, тиешенчә олылап булмый.

"Һиҗра" сүзе гарәп теленнән "бер урыннан икенче урынга күчеп китү" дигән мәгънәне аңлата. Билгеле булганча, Мәккә шәһәрендә динне тоту һәм дәгъвәт эшен алып бару бик кыенлашканнан соң, Аллаһы Тәгаләнең боерыгы буенча, сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вәссәлам һәм сәхабәләр Мәдинә шәһәренә күчеп китә. Менә шул көннәрдән башлап, нурлы Мәдинәдә иң беренче хакыйкый мөселман җәмгыяте төзелә. Мәдинәдән ислам, иман һәм Коръән нуры, әдәп-әхлак, тән һәм җан пакьлеге бөтен дөньяга тарала. Димәк, һиҗра, без мөселманнарга гына түгел, бөтен дөнья тарихына вә мәгыйшәтенә зур үзгәрешләр кертә. Һиҗра - Раббыбызның олуг нигъмәте. Һиҗри ел исәбе, миладидагы кебек үк, 12 айдан тора, әмма ай фазалары буенча хисап алып барылуы сәбәпле, 11 көнгә кыскарак була.

Каян килде соң ул һиҗри ел хисабы? Кайбер риваятьләрдә әйтелгәнчә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вәссәлам исән чагында ук аны үзе кулланган, әмма аның вафатыннан соң сәхабәләр һиҗри ел исәбе турында онытып җибәргән. Гомәр (Аллаһ аннан разый булса иде) заманы җитә. Менә шул вакытта Гомәргә дәүләтнең төрле төбәкләреннән хатлар килә, ул хатларда көне һәм ае язылган, елы билгеләнмәгән була. Шул сәбәпле, Гомәр (Аллаһ аннан разый булса иде), олы сәхабәләрдән торган шура җыеп, бу мәсьәләне күтәрә. Берәүләр беренче ел итеп Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вәссәлам туган елны сайларга тәкъдим итә. Әмма ул вакытта әле ислам динен искә дә алучы булмый, шул сәбәпле бу фикер кире кагыла. Башкалар беренче ел итеп пәйгамбәрлек башланган елны сайларга тәкъдим итә. Бу фикер дә кире кагыла, чөнки ул елны сөекле Пәйгамбәребездән башка әле җир йөзендә мөселманнар булмый. Өченчеләре исә беренче ел итеп Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вәссәламнең вафат булган елын сайларга тәкъдим итә. Ләкин башкаларның ислам тәкъвимен (календарен) кайгылы елдан башлыйсылары килми. Шул вакытта Гали ибне Әбу Талиб (Аллаһ аннан разый булса иде) тәкъдиме кабул ителә - елларны Мөхәммәд пәйгамбәрнең (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булса иде) Мәккәдән Мәдинәгә күчкән елыннан саный башларга булалар.

Бу атнада (4 нче ноябрьдә) яңа ел гына түгел, изге Мөхәррәм ае да башланды. Бу айда бер бик олы көн бар - Гашүрә көне. Ул мөхәррәм аеның 10 нчы көненә туры килә (милади календарь буенча быел 13 нче ноябрьдә булачак). Гарәп теленнән "гашүрә" дигән сүз "унынчы" дип тәрҗемә ителә. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вәссәлам, Мәккәи Мөкәррәмә шәһәреннән Мәдинәи Мөнәүвәрә шәһәренә һиҗрәт кылганнан соң, шушы шәһәрдә яшәгән яһүдләрнең бу көндә ураза тотканнарын күргән һәм алардан моның сәбәбен сораган. Яһүдләр: "Бу көнне Аллаһы Тәгалә пәйгамбәребез Муса галәйһиссәламне Фиргавеннән һәм аның гаскәреннән коткарган. Шуңа күрә без бу көнне олылап ураза тотабыз", - дип әйткән. Пәйгамбәребез салләл-

*(Ахыры 2 нче биттә.)*

## ЯҢАЛЫКЛАР

### МӨФТИЯТТӘ ЧИТ ИЛ КУНАКЛАРЫ

**Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Әл-Әзһәр университетының Фәлистыйн бүлеге ректоры Исмәгыйль Бүлбүл һәм Әл-Фәтх институты ректоры, Димәшкъ мөфтие Габделфәттах әл-Бизмә белән очрашты.** Әлеге мөхтәрәм кунаклар Казанга Россия ислам институты ачылуга 15 ел тулу уңаеннан үткәрелүче чараларда катнашу ниятеннән килде.

Мөфтияттә узган очрашу вакытында сүз фән һәм мәгариф өлкәсендә хезмәттәшлек итү хакында барды. Камил хәзрәт кунакларга "Хузур" нәшриятының гарәп телендә чыгарган басмалары, шулай ук нәзарәтнең башка проектлары хакында сөйләде. Кунаклар өйлә намазын нәзарәттә укыды. Әл-Фәтх ректоры Габделфәттах әл-Бизмә биредә эшләүчеләргә мөрәҗәгать итеп, үзенең нәсыйхәтләрен, ихлас теләкләрен җиткерде һәм Татарстан мөселманнарына иминлек-бәрәкәт сорап дога кылды.

Мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин Россия ислам институты чараларына килгән Бөтендөнья мөселман яшьләре ассамблеясы (Согуд Гарәбстаны) җитәкчесенең киңәшчесе Фәйсал Сәат ибне Җибер белән дә очрашты.

### КАМИЛ ХӘЗРӘТ ЯҢА ЧИШМӘ РАЙОНЫНДА

**Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин халык белән очрашу, андагы дини эшчәнлек белән танышу максатыннан республикабызның Яңа чишмә районына сәфәр кылды.**

Мөфти килү уңаеннан Яңа чишмә районы мәдәният йортына өлкәннәр, мәктәп укучылары, район имамнары җыелган иде. Камил хәзрәт ислам кыйммәтләрен аңлатып, аларны дин кушканча яшәргә чакырды. Үзенең күркәм нәсыйхәтләрен җиткерде, мәдрәсәләрдә гыйлем тупларга өндәде. Шулай ук ул яшьләргә мөрәҗәгать итеп, бу тормышта матди байлык, акча һәм хаким булу иң мөһим нәрсә түгел икәнлеген аңлатты. "Тормышыбызда иң мөһиме - иман!", - диде ул.

## ЯҢАЛЫКЛАР

### МӨФТИ УРЫНБАСАРЫ - ЭШЧЕ ТӨРКЕМДӘ

**Казан мэриясенең милләтара һәм динара мөнәсәбәтләрне саклау, ныгыту буенча эшче төркемнең беренче утырышы үткәрелде.** Әлеге эшче төркемгә Татарстан мөфтие урынбасары Илдар хәзрәт Баязитов та керде.

### ЯТИМ БАЛАЛАРГА ЭКСКУРСИЯЛӘР ОЕШТЫРЫЛА

**Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте балалар йортларында тәрбияләнүчеләр өчен "Күңелле каникуллар" дип аталган акция уздыра.** Балалар өчен махсус программа эшләнгән. Программада Казан циркына, аквапаркка, кинотеатрга, театрга бару, атта йөрү һәм төрле экскурсияләр оештыру каралган.

Нәзарәтнең хәйрия бүлеге хезмәткәрләре Казан девиант тәртипле балалар йортында тәрбияләнүчеләрне Казан циркына алып барды. Ял көне исә Чистай балалар йортындагы балалар Ярдәм мәчетендә булып, Күзләре күрмәүчеләрне тернәкләндерү үзәге белән танышты, аннары циркка юл тотты.

5 нче ноябрьдә Чистай балалар йортында тәрбияләнүчеләрне аквапаркка, кафега алып бару көтелә. 7 нче ноябрьгә исә Норлат балалар йортында тәрбияләнүчеләр өчен Казанга сәфәр оештыру ниятләнелгән.

### МӨСЛИМ ИМАМНАРЫ ДИНИ ГЫЙЛЕМНӘРЕН НЫГЫТА

**Бу көннәрдә Дин әһелләренең квалификациясен үстерү үзәгендә Мөслим районы дин әһелләре үзләренең гыйлемнәрен ныгыта.** 28 нче октябрь көнне Татарстан мөфтиенең мөхтәсибләр белән эшләү буенча урынбасары Рөстәм хәзрәт Хәйруллин әлеге үзәктә булып, авылларда эшләүче имамнар белән әңгәмә корды, авыл мәчетләрендәге хәлләрне белеште. Дини эшчәнлек алып баруга бәйле мәсьәләләргә кагылышлы сөйләшүдә имамнар үзләренең теләк-тәкъдимнәрен җиткерде. Аерым алганда, алар мәчетләрне җылытуга, авылдагы яшь имамнарның хезмәт стажын булдыруга кагылышлы сораулары җиткерде.

Рөстәм хәзрәт алга таба да әлеге үзәккә белемнәрен күтәрергә килгән һәр район имамы белән шушындый очрашулар үткәрергә һәм аларның теләкләрен мөфтигә җиткерергә ниятли.

Мөслим районында барлыгы 24 имам дини эшчәнлек алып бара. Укырга шуларның унбише килгән.

# ГЫЙБАДӘТ КЫЛУ ӨЧЕН ДӘ ГЫЙЛЕМ КИРӘК

**Бу атнада Россия ислам институты ачылуга - 15 ел, Коръәнхафизлар әзерләү үзәгенә 10 ел тулу уңаеннан тантаналы чаралар булып узды. Бәйрәм уңаеннан Казанда "Изге коръәнхафизлар тормышында урталык" дигән мәгариф форумы, ислам дисциплиналары һәм гарәп теле буенча VI Бөтенроссия олимпиадасы, студентларның VII Мөселман халыклары үзешчән кинофестивале оештырылды.**



Россия ислам институты 1998 нче елда ачыла. Вуз ислам теологиясе, тарих, хокук, тел, ислам икътисады юнәлешендә Россия мөселман өммәтенә хезмәт итә торган белгечләр әзерли.

РИИның төп бинасындагы чаралар изге Коръән сүрәләрен укудан һәм дога кылудан башланып китте. Тантананы ректор Рәфыйк Мөхәммәтшин ачып җибәреп, 15 еллык юбилейларын билгеләп үтүгә чиксез шатлануын белдерде. "Уку йорты өчен 15 ел вакыт - бик аз, әмма мөселман вузы өчен, бигрәк тә Россиядә - бу бик саллы дата", - диде ул.

Республика Хөкүмәте исеменнән Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары - мәгариф һәм фән министры Энгель Фәттахов сәламләде. Ул үз чыгышында илебездә югары мөселман мәгарифенең чишмә башында торган РИИ өчен 15 елның мөһимлеген билгеләп үтте. "Россиядә беренчеләрдән булып нәкъ менә Казанда шушы уку йорты оеша, ул бүген дә илебезнең әйдәп баручы ислам уку йортларыннан санала. Узган гасырның туксанынчы еллары ахырында институт дәүләт белән мөселман җәмәгатьчелеге арасындагы мөнәсәбәтләрне корыда яңа этап булды. Бу чорда күп гасырлар дәвамында илебез мөселманнарына хас булган традицияләрне Россиянең иҗтимагый-сәяси һәм рухый тормышына кайтару өчен шартлар тудыру зарурлыгын ныклап аңлау барлыкка килә", - диде министр. Э.Фәттахов сүзләренә караганда, бүгенге көндә мөселман дин әһелләрен һәм дин белгечләрен әзерләп чыгарырга кирәк. Алар күпконфессияле җәмгыятьтә яшәү үзенчәлекләрен белергә һәм аңларга тиеш. "Татарстан хакимияте органнары, мөселман уку йортларына, иң беренче чиратта, Россия ислам институтына ярдәм күрсәтеп, шушы мөһим максатларны тормышка ашыруны күз алдында тота. Мөселман уку йортлары, бигрәк тә вузлар төп бурычны үтәргә - белемле, югары әзерлекле дин әһелләрен хәзерләп чыгарырга тиеш. Шунысы көн кебек ачык: бүгенге шартларда югары уку йортлары моның белән генә чикләнә алмый. Шуңа күрә алар алдында мөселман зыялыларын һәм дин белгечләрен әзерләп чыгару бурычы тора. Җәмгыятьтә исламга каршы карашларның таралуын чикли алырлык, ислам турында мәгълүматы булган һәм толерант мөнәсәбәтләрне дәвам итә алырлык зыялылар катлавы булырга тиеш", - диде Энгель Фәттахов, алга таба да РИИның яшь коллективының бу бурычларны үтәүгә үзеннән зур өлеш кертәчәгенә ышаныч белдереп.

КФУның Халыкара мөнәсәбәтләр институты директоры Рамил Хәйретдинов та: "Бу еллар эчендә РИИ зур һәм күпләргә үрнәк булырлык юл үтте", - дип белдерде. Ул Дәүләт Эрмитажы директоры Михаил Пиотровскийның: "Академик ислам белеме белән ислам дини тәгълиматы арасында бәйләнеш булырга тиеш. Гуманитар фәннәр дин һәм гыйлем, дин һәм фән арасында күпер булып тора", - дигән сүзләрен китереп, гуманитар фәннәрнең, бигрәк тә исламны өйрәнү фәненең мөселман мәгариф системасын оештыруның нигезендә торуына басым ясады. Рамил Хәйретдинов сүзләренә караганда, бүген Россия ислам институты мөселман белеме бирүдә әйдәп баручылардан санала. КФУның һәм РИИның тарих һәм ислам мәдәнияте өлкәсендә белгечләр әзерләү буенча федераль программасын тормышка ашыруы дөньяви фәннәр һәм ислам гыйлеменең тыгыз бәйләнешләренә ачык мисал булып тора.

Татарстан мөфтие урынбасары, үзе дә шушы уку йортын тәмамлаган Рөстәм хәзрәт Хәйруллин институтның дин әһелләрен әзерләвен, имамнарның квалификациясен күтәрүгә зур өлеш кертүен билгеләп үтте.

Чит илдән килгән кунаклар да Россия ислам институты эшчәнлеген уңай яктан гына бәяләп үтте. Димәшкъ шәһәре мөфтие, "Әл-Фәтх" институты ректоры Әбдүлфәттах әл-Бизмә биредә элек тә булган. Шуңа күрә ул вузның потенциалын югары бәяли. Аның сүзләренчә, Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт кылу өчен дә гыйлем кирәк. Ә Россия ислам институтында шуңа өйрәтәләр дә. Согуд Гарәбстаны Корольлегенең Россиядәге Тулы вәкаләтле вәкиле Хәсән Гали Җәгъфәр дә Казандагы вузның төрле өлкәләрдә белем бирүдә әйдәп баруын ассызыклап үтте.

**Римма ГАТИНА, "Татар-информ"**

# МӨХӘРРӘМ АЕ ҺӘМ ҺИҖРИ ЯҢА ЕЛ ҖИТӘ

***(Ахыры. Башы 1 нче биттә.)***

лаһу галәйһи вәссәлам аларга болай дип җавап биргән: *"Сезгә караганда Муса пәйгамбәр безгә якынрак"*. Рәсүлебез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәссәлам шушы көнне уразада булган. Ул үзенең өммәтен, мөэмин-мөселманнарны да бу көндә ураза тотарга өндәгән. Гашүрә көнендә башка күп кенә бөек вакыйгалар да булган. Бу көнне Бөек Раббыбыз дөньяны, Адәм галәйһиссәламне ярaлткан, Нух галәйһиссәламнең көймәсе тауга килеп җиткән, Ибраһим галәйһиссәлам туган һәм мәҗүсиләрнең учагыннан коткарылган, Әюб галәйһиссәлам авыруыннан терелгән, Йосыф галәйһиссәлам олы дәрәҗәләргә ия булган һ. б.

Мөхәррәм ае да, рәҗәп, рамазан һ. б. айлар кебек үк, изге-шәрәф ай булып санала. Әгәр дә ай буе ураза тоту хәлебездән килмәсә, мөхәррәм аеның унынчы һәм унберенче көннәрендә генә булса да ураза тотарга тырышырга тиешбез. Ә иң хәерлесе - рәттән өч көн тоту: мөхәррәм аеның 9 нчы, 10 нчы һәм 11 нче көннәрен ураза белән уздырсак, Аллаһның чиксез рәхмәтләренә ирешербез.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вәссәламнән: "Мөхәррәм аеның Гашүрә көнендә ураза тотсаң нинди савапларга ирешергә була соң?" - дип сорагач, ул: *"Узган елыгызның гөнаһларын, хата-кимчелекләрен Аллаһы Тәгалә гафу итәр, истигъфар кылыр"*, - дигән.

Мөхәррәм ае - изге ай. Бу айда кылынган гамәл-гыйбадәтләребезнең, игелекле эшләребезнең әҗер-савабын Аллаһы Тәгалә бик күп мәртәбәләргә арттыра һәм аның хакыйкый әҗерен без Аллаһ Раббыбыз хозурындагы Кыямәт көнендә генә аңлаячакбыз. Ләкин, шул ук вакытта, адәм баласы гөнаһ кылса, аның гөнаһлары өчен дә җәза булачак. Шуны истә тотсак иде. Хакыйкый инану белән инанып, мөхәррәм айларының һәр көнен гамәл-гыйбадәт кылып уздырырга тырышсак иде. Нәфел уразалары, нәфел намазлары, игелекле эшләр булсынмы, иң мөһиме - шуларны кылырга ашыгып-ашкынып торсак иде. Бер-беребезгә мәрхәмәтле булып, иминлек таратсак иде. Кайберәүләр: "Гыйбадәт фәкать уразадан, намаздан гына гыйбарәт", - дип уйлый. Болай дип уйлаучылар зур хата кыла. Гыйбадәтебез - бер-беребезгә игелек кылу, мәрхәмәтле булу, шәфкатьлелек күрсәтү, ярдәм кулы сузарга тырышу; ярдәмнең нindие дә - матдимы яисә рухыймы - безнең өчен гыйбадәт икәнлеген онытмыйча, Аллаһка ялварып, игелекле эшләр кылырга ашыксак иде. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вәссәлам дә: *"Киләсе елның мөхәррәм аен күрә алсам, һичшиксез, ураза тотар идем"*, - дип әйткән.

Менә безгә Аллаһ Раббыбыз быелгы мөхәррәм аен күрергә насыйп иткән икән, ураза тотып, гамәл-гыйбадәттә булып, Раббыбызның чиксез рәхмәтенә - шушы дөньяның да, ахирәт тормышының да бәхет-сәгадәтенә ирешергә Аллаһ Раббыбыз һәрбарчаларыбызга да насыйп итсә иде.

**Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең дәгъвәт бүлеге**

# Намаздан соң кул бирешүнең хикмәтләре



**"Дин вә мәгыйшәт" газетасы редакциясенә ислам диненә, дини йолаларны үтәүгә кагылышлы бик күп сораулар килә. Бүгенге сәхифәбездә шуларның кайберләренә Үзәкләшкән дини оешма - Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН җавап бирә.**

**СОРАУ.** *Коръән укыган вакытта мин Пәйгамбәрне (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булса иде) искә алуларын ишетсәм, миңа бу вакытта кыйраәтне калдырып торып, салават әйтергә кирәкме?*

**ҖАВАП.** Мондый очракларда кыйраәтне калдырып торып, салават әйтергә кирәкми, салават әйтүне Коръән укуыңны тәмамлагач башкарырга мөмкин.

"Әл-Фәтава Әл-Һиндия" китабында болай дип әйтелә:

Әгәр дә Коръән укыган кеше, Пәйгамбәр (с. г. в.) исемен ишетсә, аңа салават әйтү ваҗиб түгел; Коръән укуын тәмам иткәч, салават әйтүе яхшы булыр. Бу турыда "Әл-Йәнәбиг" китабында әйтелгән.

**СОРАУ.** *Әгәр дә мин Пәйгамбәр (с. г. в.) исемен Коръәндә укысам, миңа бу вакытта салават әйтергә кирәкме?*

**ҖАВАП.** Сезнең салават әйтми генә Коръән укуыгызны дәвам итүегез яхшырак булыр.

"Әл-Фәтава Әл-Һиндия" китабында бу турыда болай диелә:

Әгәр дә кеше Коръән укый һәм [Коръәндә] Пәйгамбәр (с. г. в.) исемен укый икән, бу вакытта салават әйтүгә караганда, аны "назм" һәм "таглиф" белән (ягъни, Коръәндә иңдерелгәнчә) уку яхшырак булыр. Әгәр дә ул Коръән укуын тәмам иткәч, салават әйтсә - яхшы; әгәр дә ул укуын тәмам иткәч, салават әйтмәсә - бу ваҗиб түгел; бу турыда "Әл-Мөлтәкат" китабында әйтелгән.

**СОРАУ.** *Мөгаен, Коръән уку яхшыракмы, әллә инде Пәйгамбәргә (с. г. в.) салават әйтүме, дип күп кешеләр үзләренә сорау куядыр. Чынлап та, кайсы яхшырак?*

**ҖАВАП.** Намаз укырга рөхсәт ителмәгән вакытларда (кояш чыкканда, кояш зәвәлдә торганда, кояш баеганда), Пәйгамбәргә (с. г. в.) салават әйтү яхшы, ә калган вакытларда Коръән уку өстенлерәк исәпләнә.

"Әл-Фәтава Әл-Һиндия" китабында болай дип әйтелә:

Имам Әл-Баккалидан: "Коръән уку яхшыракмы, әллә инде салават әйтүме?" - дип сораганнар. Ул болай дип җавап биргән: "Кояш чыкканда һәм намаз уку мәкруһ булган вакытларда (кояш чыгу, кояш зәвәлдә тору, кояш баю) Коръән укуга караганда, Пәйгамбәргә (с. г. в.) салават әйтү, дога уку, тәсбих әйтү яхшырак, чөнки "сәләфү-салих" (ягъни сәхабәләр һәм табигыйннар) бу вакытларда Коръән укымаган, ә тәсбих әйткән. Бу турыда "Әл-Гараиб" китабында әйтелгән.

**СОРАУ.** *Әгәр дә без Пәйгамбәрнең (салләллаһу галәйһи вәссәлам) исемен ишетәбез икән, аны ишеткән саен салават әйтергә тиешбезме?*

**ҖАВАП.**

Әгәр дә кеше Пәйгамбәр (с. г. в.) исемен ишетә икән, ул аңа салават әйтергә тиеш, әгәр дә ул аны мәҗлестә берничә тапкыр ишетсә, бу вакытта салават әйтү буенча галимнәрнең фикерләре төрлечә. Мәсәлән, аларның кайберләре бер тапкыр гына салават әйтергә кирәк ди, бу турыда "Фәтава Кадыхан" китабында да әйтелә. Бу мәсьәлә буенча "Әл-Кунья" китабында түбәндәгечә аңлатылган. Имам Тәхави, Пәйгамбәр (с. г. в.) исемен ишеткән саен салават әйтү - ваҗиб гамәл (мәҗбүри кылынырга тиешле гамәл) булып тора дип аңлата, аның фикеренчә, мондый фәтва иҗмаг (галимнәрнең гомуми бер фикергә килүе) буенча чыгарылган фәтва; бу турыда Әл-Вәлвәлиҗи" китабында да әйтелә (бу "Тәкъва"лыкка якын булып тора).

Әгәр дә кеше Пәйгамбәр (с. г. в.) исемен ишетү белән салават әйтми калса, бу аның үтәлмәгән бурычы булып кала, ләкин, Аллаһы Тәгаләгә зикер әйтүдән аерматы бар, аны әйтми калу өчен башка урын булмаячак. Чөнки кешенең бар вакыты да Аллаһка зикер, тәкбир әйтү өчен билгеләнгән. "Сәлам" гыйбарәсен (мәсәлән, "галәйһиссәлам") салават әйтү (мәсәлән "галәйһиссәлят") алмаштыра ала. "Әл-Гараиб" китабында да шулай аңлатыла.

**СОРАУ.** *Исламда намаздан соң кул кысышуның хикмәте турында тәфсилләбрәк аңлатсагыз иде.*

**ҖАВАП.**

Соңгы вакытларда мөселманнар арасында намаз укыганнан соң кул кысышу мәсьәләсе буенча аерым бер тенденция башланып китүе күзәтелә.

Бер яктан, бу гамәлне хупламаучыларның аны катгый кире кагуларын, ә икенче яктан, аны хуплаучыларның мондый практиканы кулланмаучыларны сүгүен ишетергә туры килә. Аллаһы Тәгаләнең ярдәме белән без бу мәсьәләгә ачыклык кертергә тырыштык.

"Әд-Дүррел Мохтар" китабының "Әл Хәдр вәл Ибаһа" бүлегендә имам Хаскафи болай дигән:

Мөсәфәхә (кул кысышу) - рөхсәт ителгән гамәл, чөнки ул бик борынгыдан килгән мөтәвир сөннәт (бик борынгыдан өзлексез гамәл кылынып килгән сөннәт). Пәйгамбәр (с. г. в.) болай дип әйткән: "Мөселман туганының кулын кысып, аны селкеп алган кеше, ул кешенең гөнаһларын селкеп төшерер".

Бу авторның "Әд-дурар", "Әл-Кәнз", "Әл-Викая", "Ән-Нукая", "Әл-Маҗма", "Әл-Мөлтәкә" һәм башка китапларында китерелгәннәрнең эзеннән барып, гомуми нәтиҗәләр чыгаруы - мөсәфәхәтнең (кул кысышуның) икенде намазыннан соң да рөхсәт ителгән гамәл булуын ачыклый.

Ә бу гамәлне бидгать дип атаучылар аның мөбах хәсән бидгать (мөбах яхшы бидгать) булуы турында яза.

Бу мәсьәлә имам Нәвавиның "Әл-Әзкәр" китабында һәм башка галимнәр китапларында да шулай итеп аңлатыла.

Имам Нәвавиның "Әл-Маҗма" китабы шәрехчесе аның "иртәнге һәм икенде намазлардан соң мөфәсәхә эшләүнең бернинди дә начарлыгы юк һәм аның бу гамәлне "мөбах хәсән бидгать" гамәл" дип билгеләве бу билгеләмәләрне үзара ярaштыру (өчен эшләнгән) дип аңлата.

Ибне Габидин "Раддел Мохтар" китабында "Әл-Әзкәр"дәге имам Нәвавиның сүзләрен аңлатып болай дип әйтә:

Имам Нәвави бу китабында: "Белегез, мөселманнарның очрашкан саен мөсәфәхә кылулары (кул кысып күрешүләре) - ул мөстәхәб гамәл, ә иртәнге һәм икенде намазыннан соң бу гамәлне кылуга шәригатьтә бернинди нигез дә юк, тик бу очракта да, бернинди начарлык та юк, чөнки, "мөсәфәхә"нең нигезе - сөннәт. Мөселманнарның кайбер халәтләрдә (хәлләрдә) бу өлкәдә артык тырышлык күрсәтүләре, ә (кайбер) күп халәтләрдә ("мөсәфәхә"не) кылмый калулары (хәтта аларның күп өлешендә дә), аларның артык тырышлык күрсәткән "кайбер бу халәтләрен" - сөннәтләр исемлегеннән чыгармый", - дигән.

Ибне Габидин болай дип дәвам итә:

"Шәех Әбел Хәсән әл-Бикри:

"(Имам Нәвави) билгеләп киткән иртәнге һәм икенде намазыннан соң "мөсәфәхә кылу" - ул вакытларның гадәте булган", - дигән. Шул рәвешле гамәл кылу һәр намаздан соң (безнең вакытларда да була). Шулай ук, имам Әш-Шурунбуләли дә имам Әш-Шәмси әл-Ханутиның "мөсәфәхә кылу" турында әйткән сүзләре буенча ошаш мәгълүмат китерә.

Имам Әт-Тахтави үзенең "Хашия" һәм "Маракил-Фәлях" дигән хезмәтләрендә болай дип әйтә:

"Бу да (мөсәфәхә кылу да), очрашкан һәм һәр намаздан соң - сөннәт".

Ә шәех Габдел-Гани ән-Нәблүси намаздан соң "мөсәфәхә кылу" мөнәсәбәтле болай дип әйткән:

"Бу (мөсәфәхә кылу) - кул кысып күрешүнең гомуми кагыйдәләре сөннәтенә керә".

Алга таба без намаз укыганнан мөсәфәхә кылуның дөрес икәнлеге турында бер хәдис китерәбез:

"Аби Җухайфадан түбәндәгеләрне китерәләр:

"Аллаһның Рәсүле (с. г. в.) төш вакытында "Батха" дигән җиргә килеп тәһарәт алды һәм аннан соң, ике рәкәгать өйлә, ике рәкәгать икенде намазларын укыды, аның алдында сөңге тора иде. Аның каршыннан бер хатынкыз үтеп китте һәм (намаздан соң) кешеләр, Пәйгамбәрнең (с. г. в.) каршына килеп басып, аның ике кулын кулларына алып үзләренең битләренә куя, алар белән битләрен ышкый башлады". Аби Җухайфа алга таба болай дип дәвам итә: "Мин дә килеп аның ике кулын кулларыма алдым да үз битемә куйдым. Аның куллары миңа боз кебек салкын, миск кебек хуш исле тоелдылар" (имам Бохари. "Фәтхел-Бари" 6/565).

Явиз ибне Әсвадтан шуны тапшыралар: ул Пәйгамбәр (с. г. в.) белән намаз укыган һәм шул сүзләрне әйткән:

"Намаздан соң кешеләр торып басып аның янына килде дә, кулларын кулларына алып, үз битләрен сыйпый башлады. Мин дә аның кулларын кулларыма алдым, алар белән битемне сыйпадым, алар миңа боздан да салкынрак, мисктан да хуш ислерәк тоелды".

Мөсәфәхәне ничек кылуга (кул кысышуга) мөнәсәбәтле "Әд-Дүррел Мохтар"да шундый сүзләр бар:

"Әл-Кунья" китабында болай диелгән: "Мөсәфәхә"не ике куллап кылу - сөннәт".

Ә "Раддел-Мохтар"да бу мәсьәлә буенча шундый юллар бар:

"Мөсәфәхә - бер кешенең учларын икенче кешенең учларына тидереп күрешүе, бу вакытта бер-берләренә караулары. Ә бармаклар белән генә орыну мөсәфәхә түгел; ә "сәлам" дип әйткәч, кулларда күрешкән вакытта ниндидер чүпрәк яки башка материалдан өстәмә катламсыз (бияләйсез), баш бармакны (икенче кешенең) баш бармагына орындырып, ике куллап мөсәфәхә (кылу) - сөннәт. Чөнки, баш бармакта сөюне арттыра (үстерә) торган кан тамыры (бар). Шулай ук, бу Кухистани һәм башкалар китергән хәдистә күрсәтелгән".

# НИ ЧӘЧСӘК, ШУНЫ УРЫРБЫЗ!

**Адәм баласын тәрбияләүгә килсәк, иң элек тәрбия нигезенә - Аллаһның Коръәни-Кәрименә һәм Пәйгамбәребезнең (с. г. в.) сөннәтенә әйләнеп кайтабыз. Раббыбыз безгә яшәү тәртибе итеп Коръәни-Кәримне җибәрде. Раббыбызның вәгъдәсе, Коръәни-Кәримнең хөкемнәре Кыяматкә чаклы үзгәрмәячәк. Без шул юлдан барсак, бер дә адашмабыз, иншә Аллаһ.**

"Һәрбер Адәм баласы фитрый иман белән туа, аннан соң әти-әниләре аны яки яһүди, яки нәсари, яки мәҗүси итә", - дип әйтелә Пәйгамбәребезнең (с. г. в.) хәдисендә. Әлбәттә, баланы әни карынында булганда ук тәрбияли башларга кирәк, чөнки Адәм баласының бөтен тереклеге шуннан башлана. Әйе, әгәр дә безнең агачыбыз яхшы җимеш бирсен дисәк, агачны утыртканчы башта урынын сайларга, җирен әзерләргә, аннан соң эшкәртергә, суын вакытында сибәргә кирәк. Шул чакта гына җимешебез тәмле булачак. Балага 6-7 яшь тулганчы үзен акыл белән идарә итүне сеңдерергә кирәк. Бу нәрсә дигән сүз соң? Беренчедән, яхшыдан яманны аера белергә өйрәтү. Икенчедән, хак белән нахакны (алдашмаска, урлашмаска) дөрес итеп аңлату. Һәрбер бала ислам динендә булган хәлдә дөньяга килсә дә, әти-әнисенең яки ялган тәрбиячеләр һәм укытучылар тәрбиясе нәтиҗәсендә аның төрле юлга кереп китүе ихтимал, шуңа күрә бу нәрсәгә бик нык игътибар бирергә кирәк.

"Кечкенәләргә хөрмәт күрсәтмәүче һәм өлкәннәрнең хакларын үтәмәүче кеше - бездән түгел", - ди Аллаһның рәсүле (с. г. в.). Җәмгыятьнең төзеклеге дә, нигездә, өлкәннәрне кадерләү һәм кечкенәләргә карата мәрхәмәтле булуга бәйле. Кечкенәләргә мәрхәмәтле булу, аларны һәрвакыт иркәләп тору дигән сүз түгел, бәлки аларга шәфкать юлы белән дөньяви һәм дини тәрбия бирү. Ата-ана үзенең баласына яхшы тәрбия һәм әдәп-әхлактан да артыграк бүләк бирә алмас. Дини гамәлләрдә тәрбияләнгән балалар һәрвакытта аерылып торалар, чөнки бала аякка басып, әз-мәз сөйләшә башлагач, шул дини гаиләдә булган хәяттә тәрбия ала башлый. Ягъни әти-әнисе намаз укуын күрсә, ул алар артыннан кабатлый. Бала 3-4 яшендәге чорда тирә-юньне игътибар белән күзәтүчән, ә аннан соң ишеткән-күргәннәрен гамәлдә дә кулланырга тырыша. Бигрәк тә сөйләм тәртибен, үз-үзен тоту кагыйдәләрен өйрәтү кирәк бу яшьтә. Бала кечкенәдән үк үзенең динен, телен, гореф-гадәтләрен белергә тиеш. Бу - безнең бурыч. Милләт һәм дин-ислам тарихын белмәгән баланы камил тәрбия алган дип әйтеп булмый. Бөек рус галиме, педагог һәм психолог Константин Ушинский: "Милли тәрбия генә көткән нәтиҗәне бирә, тулы канлы шәхесләр формалаштыра", - дигән.

Безне совет чорында милләтсез, динсез кавем итеп тәрбияләргә тырышып карадылар, тик нәтиҗәсе булмады, чөнки татар-мөселман гаилә тәрбиясе бетмәде - әлхәмдүлилләһи шөкер, әти-әниләребез, әби-бабайларыбыз безне тәрбиядән ташламады. Кызганыч, бүген дә милләткә, исламга каршы булган кайбер тар фикерле адәмнәр: "Исламда милләт юк, милли үзенчәлекләргә, гореф-гадәтләргә урын юк", - дип акыл сатарга ярата. Ә бит милләтләр кирәк булмаса, Аллаһ аларны яраltмас, аңлатып аятьләр индермәс иде. Милли үзенчәлекләрне санга сукмау, гореф-гадәтләрне инкарь итү Аллаһка каршы килү була. Аллаһ Раббыбыз Коръәни-Кәримдә ("Хөҗүрәт (Бүлмәләр)" сүрәсе, 13 нче аять): "Йәәәә әййүһәннәәсү иннәә халәконәәкум миң зәкәриү үә үнсәә үә җәгәлнәәкум шүгүүбәү үә кабәәәә илә литәгәәрафү, иннә әкрамәкум гиндәллааһи әткаакум", ягъни: "Әй, адәм балалары! Хактыр ки, Без сезне бер ир, бер хатын итеп яралттык. Бер-берегез белән аралашыгыз дип, сезне кавемнәр вә кабиләләргә аердык. Хактыр ки, гөнаһ кылудан курыккан кеше Аллаһ каршысында иң олы абруй казаныр. Шөбһәсездер ки, Аллаһ барысын да белеп, барысыннан да хәбәрдар булып тора", - диде. Төрле дин, милләт халыкларның Җир йөзендә күплеге, төрлелеге, бер-берсен хөрмәт итеп яшәүләре генә гармония тудыра. Милли тәрбия, милли аң, милли горурлык башка халыкларны кимсетү хисабына булырга тиеш түгел. Аллаһ Раббыбыз Коръәндә: "Йәәәә әййүһәлләзиинә әәмәнүү ләә йәсхар каумүм миң каумин гәсәәә әй йәкүүнүү хайрам минһүм" ("Хөҗүрәт" сүрәсе, 11 нче аять), ягъни: "Әй, мөэминнәр. Бер төркемегез икенчесен мыскыллап көлмәсен (кимсетмәсен). Бәлки алар (мыскыллаучыдан) күпкә яхшыдыр", - диде. Гарәп, төрек, европалы, йә руска охшарга тырышып, үз милләтебезгә түбәнсетеп карасак, телебезне, динебезне хөрмәтләми инкарь итсәк, әлеге илаһи аятькә каршы килүчеләр булмабызмы? Шул ук вакытта башка бер милләтне кимсетеп карау да дөрес түгел. Аллаһ Раббыбыз безгә бу аятьтә: "Мөэминнәр", дип эндәште, димәк, иманлы тәрбияләнгән кеше үз милләтенә дә түбәнсетеп карамас, башка милләтне дә кимсетмәс. Менә боларны ул-кызларыбызга ныклап җиткерергә кирәк, җәмәгать.

Җир йөзендә бик күп булсак та, башка күпсанлы, мәсәлән, рус халкына караганда Россиядә без бик аз. Безнең кебек милли һәм дини азчылыкны тәшкил итүче халыкка үзебезнең милли үзенчәлекләрне, динебезне һәм мәдәниятебезне саклау аеруча мөһим. Бу мәсьләгә җитәрлек игътибар бирелмәсә, халык югалыр. Шундый аяныч хәлгә калмас өчен һәрберебез хәлебездән килгән кадәр динебез вә милләтебез өчен тырышып файдалы эшләр эшләргә тиешбез. Аларның иң мөһиме - бала тәрбияләү. Бу - милләтебезнең иң олуг вазыйфаларының берсе.

"Сөй халыкның дөньясын!" - ди шагыйрь, ягъни аның яшәү рәвешен, гореф-гадәтләрен, телен, мәдәниятен, әдәбиятын, сәнгатен кабул итәргә, буыннан-буынга күчеп килгән традицияләрне саклап яшәргә өнди сөекле шагыйребез. Үз халкыңның дөньясын яратыр өчен иң элек аны белергә, шул мохиттә үсәргә, тәрбияләнергә кирәк. Халыкның язылган һәм язылмаган канунннары, гореф-гадәтләре кечкенәдән баланың канына, аңына сеңдерелергә тиеш, шул рәвешчә һәр милләтнең, халыкның үз мәдәнияте, милли йөзе барлыкка килә.

Хәзерге заман яңа шаукым алып килде. Соңгы елларда яшьләрнең күпләп шәһәрләрдә төпләнеп калуы, шәһәрләрдә генә түгел, авыл мәктәпләрендә дә ана теле дәресләренең кыскартылуы, укытылмавы, балалар саны аз булган мәктәпләрнең ябылуы, озак еллар ил күләмендә алып барылган атеистик тәрбия, имамнарның тәрбияләнмәве, мәчет-мәдрәсәләрнең эшләмәве берничә яшь буынны ислам диненнән, татар теленнән, әдәбиятыннан, милли мәдәнияттән читләштереп өлгерде. Ә соңгы елларда, кызганыч ки, татар балалары бер-берсе белән рус телендә аралаша башлады, әби-бабайларыбыздан килгән гореф-гадәтләргә игътибар кимеде. Элек гөрләп торган авыллар бетүгә таба бара, авылларда инде элек уздырыла торган халык бәйрәмнәре, өмәләре үткәрелми, яшьләр мәчеткә йөрми. Әле күптән түгел бер имам күз яшьләре белән ачынып та, оялып та: "Быел, хәзрәт, зират өстен чабып булмады", - ди. Ә бит бу, безнең якта, элек-электән килгән гореф-гадәт. Иншә Аллаһ, яңадан торгызылган гореф-гадәтләребез дә җитәрлек. Монда шул ук гошер сәдакасын җыеп, аннан өлеш чыгару, зиратларга барып өлкәннәрнең каберләрен барлау кебек дини дә, милли дә булган матур йолаларыбызны мисал итеп китерергә була.

Телебезне, гореф-гадәтләребезне онуту безне руслаштыруга, поляклаштыруга, литвалаштыруга, шуның белән бергә динебездән ваз кичүгә дә китерә. Үз заманында Шиһабетдин Мәрҗани хәзрәтләре дә: "Өч төрле әйбер диндә булмаса да, динне саклый, алар: милли тел, милли кием, милли гореф-гадәт", - дип язды. Әби-бабайларыбыз руслардан аерылып тору өчен яулыкны да үзләренчә бәйләгәннәр, түбәтәйләрен дә салмаганнар, сакалны да матур итеп кыркып, үзләренчә йөрткәннәр. Ул вакытта: "Татарның башта башы төшә, аннан соң гына түбәтәе", - дигән әйтем йөргән. Никадәр горурлык һәм үз-үзеңне хөрмәт итү бу гадәттә. Татар кешесе элек түбәтәен бер дә салмаган. Әле дә бу гадәт бетмәгән, аны тагын да яңартырга кирәк. Берәр бәйрәм, туй булса, безнең халык башына түбәтәйне киеп куя. Бүген түбәтәй кияргә оялучы яшьләребезгә мисалны үзебез күрсәтик, мөхтәрәм имамнар, алар бу турыда белми йөрмәсеннәр, түбәтәйне искелек калдыгы дип кенә санамасыннар. Әгәр баланы кечкенәдән түбәтәй киертеп үстерсәк, ул олыгайгач та аны салмаячак. "Искелек калдыгы" дип онытылган, ташланган традицияләребезне яңадан көндәлек тормышка кайтарсак, балаларга шуны өйрәтсәк, ничек яхшы булыр иде, чөнки үз халкының рухый һәм матди мирасын сакламаган милләт беркайчан да алдынгы була алмый, үткәнен, ата-бабай мирасын калдырмаган халык алга бармый.

Бала бит ул ак кәгазь кебек, аңа тәрбия ярдәмендә төрле нәрсә язарга була. Шуңа күрә ул яхшы тәрбияне дә, яман юлга алып бара торган бозык тәрбияне дә кабул итәргә мөмкин. Вакытында чарасын күреп, балага яхшы тәрбия бирү, аны яман юллардан саклау - әти-әнинең баласына бирә ала торган бүләкләрнең иң кыйммәтлесе.

Аллаһының рәхмәте белән динебезнең ишекләре ачылып киткәнгә ике дистәдән артык ел булса да, кызганыч, балаларга караганда әти-әниләрнең дингә якынаюы бик акрын бара әле. Туксанынчы еллардан соң күп кенә әти-әниләр балаларын мәчетләр каршында оешкан дини укуларга йөртә, мәдрәсәләргә бирә башладылар. Балаларын намазга, ураза тотарга әти-әниләре түгел, киресенчә, күпчелек очракта балалар үзләре аларны Аллаһының юлына өндәделәр. Бүген мәдрәсәләргә килгән шәкертләрнең әти-әниләренең 90 проценты намаз, сәҗдә әһелләре түгел. Ә мәдрәсәләргә теләп китерүләренең максаты - балаларын урам йогынтысыннан саклап калу.

Әгәр әдәп-әхлак, милли аң, ислам диненә хөрмәт, ихтирам орлыкларын ихлас мәхәббәт белән чәчсәк, киләчәктә файдалы җимешләрен үзебез үк мул итеп җыеп алырбыз. Халкыбыз: "Ни чәчсәң, шуны урырсың", - дип бик акыллы әйткән. Халык әйтсә, хак әйтә ул.

**Ильяс хәзрәт ҖИҺАНШИН,**
**Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсә директоры**

# БАЛА ТӘРБИЯЛӘҮНЕҢ УН КАГЫЙДӘСЕ

**Баланың дөньяга килүе бу дөньядагы барлык нәрсәләр кебек үк Аллаһы Тәгалә ихтыярында. Сезнең үзегездән бәйле булганнары түбәндәгеләр: аның дөньяга килүен моңа әзер булып каршы алу; балигъ булганга кадәр аны саклап үстерү, тәрбияләү, аның турында кайгырту; яхшы тәрбия бирү (үзенең кылган гамәлләре өчен җавап бирә ала торган мөстәкыйль шәхес тәрбияләү).**

Һәр бала бу дөньяга үз миссиясе белән килә. Шуның өчен һичбер очракта да аның язмышын үзгәртергә тырышмагыз, аңа үз сәләтләрен, укуга, уеннар уйнарга, аралашырга, башка төрле эшчәнлеккә булган табигый омтылышларын үстерергә мөмкинлек бирегез.

Баланы ничек бар - шулай кабул итегез. Күпләр баланың "шәхес механизмы" үсүен туктата, яхшы ата-ана була белү - нәкъ менә баласының үсешен һәм камиллеккә омтылуын тәэмин итә белү дигән сүз бит инде. Үз балаларыгызны ярагыз, аларны бәяли, эш һәм омтылышларында дәртләндерә белегез.

Аллаһның Рәсүленең (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булса иде) үз оныклары Хәсән белән Хөсәенне иркәләп үпкәнен күреп, сәхабәләрнең берсе: "Ун балам бар, минем аларны бервакытта да үпкәнем юк", - дигән. Аллаһның Рәсүле аңа: "Аллаһ синең күңелеңнән мәрхәмәтлелекне алып ташлагач, мин нишли алам соң?" - дип җавап биргән.

Һәр бала да - шәхес! Балагыз белән аралашкан вакытта, аның фикер, хис һәм эмоцияләрен илтифатсыз калдырмагыз. Кайвакыт балалар бездән дә акыллырак була. Чөнки алар күңеленнән хакыйкать ташкыны, җәмәгатьчелек фикере кебек үк, бернинди дә киртәсез агыла. Бу очракта "алай дип әйтү кабул ителмәгән" кебек бернинди дә искәрмәләр юк. "Һәрбер яңа туган бала дөньяга фитрәт халәтендә килә", - диелә хәдистә. Ягъни, һәр бала, туган вакытта төрле бозыклыклардан һәм явызлыклардан азат, бары тик тәрбия һәм тирәлек кенә аны начар кешегә әйләндерә. Шуның өчен балагызның табигыйлегеннән курыкмагыз, аңа игътибарлы булыгыз, аның сөйләгәннәрен тыңларга өйрәнегез, ә кайвакыт хәтта бу "яшь профессорыгыз" белән киңәшләшегез дә.

Балагызга бервакытта да ялган сөйләмәгез! Бервакытта да! Ул "белмәскә тиеш" булган бернинди хакыйкать тә юк. Шаярып та ялган сөйләргә ярамый. Әгәр дә балага турыдан-туры дөресен сөйләргә нигезле берәр сәбәп мөмкинлек бирми икән, сез аңа барысын да ачык кына әйтергә нәрсә комачаулаганын аңлатыгыз. Эндәшми, аңлатмый калу да ярдәм итмәячәк, чөнки балалар бик тәэсирләнүчән була. Балалар белән үзара ышанычлы мөнәсәбәтләрне аларның балачагыннан ук урнаштырырга тырышыгыз.

Балагызның тән, гәүдә төзелешенә бәйләнмәгез. Баланың гәүдәсен тотышы - аның үз-үзенә ышанучанлыгы һәм куркынычсызлыгының чагылышы. Әгәр дә балагыз бөкрәебрәк йөрмәсен дисәгез, анда куркынычсызлык тойгысы тудырырга тырышыгыз: аны артык ачуланмагыз, кимсетмәгез, түбәнсетмәгез, уңайсыз киемнәр киеп йөрергә мәҗбүр итмәгез. Баланың сәламәтлеге һәм үзен уңайлы хис итүе аның тышкы кыяфәтеннән әһәмиятлерәк.

Балагыз мөмкин кадәр мөстәкыйль булсын. Аңа ул үзе эшли алмаган эшләрендә генә ярдәм итегез. Вакыт үткән саен аның мөстәкыйльлеген арттыра барыгыз.

Үз балагызны башка балалар белән чагыштырмагыз. Ул, бу дөньяның калган 7 миллиард кешесе кебек үк, үзенә бертөрле. Үз вакытында моны аңлый алу - аны тәкәббер булудан һәм үз-үзен таныту теләге белән яшәүдән аралаячак.

Үз балагызга, аның яхшы сыйфатлары потенциалына ышаныгыз. Бу ышаныч сезгә киләчәктә балагызның шәхси һәм профессиональ уңышлары белән горурлану булып кире кайтачак.

Бусы - ата-аналар өчен кагыйдә. Балаларга тәрбия бирүнең зарурлыгына да карамастан, сезнең шәхси тормышка, шәхси эшчәнлеккә дә хокукыгыз бар. Балаларыгыз үзегез өчен күпмедер вакытыгызны сарыф итүегезне (шөгыль, ял итү, күңелле башка вак-төякләр) хөрмәт итәргә өйрәнеп үссен. Үзегезне кайгыртырга онытмагыз, шул вакытта башкаларны кайгырту сезгә зур шатлык һәм ләззәт китерер.

**Ася ГАГИЕВА**

# "МОНДЫЙ ЮБИЛЕЙГА БАРМАУ ГӨНАҺ БУЛЫР"

**Арча районы Яңа Кырлай мәчетендә олы тантана булды - мәчет үзенең 100 еллык юбилеен билгеләп үтте. Бу уңайдан биредә зур мәҗлес оештырылды. Анда Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең дәгъвәт бүлеге белгече Тимергали хәзрәт Юлдашев та катнашты.**



Тантаналы мәҗлесне Яңа Кырлай мәчете имамы Вазыйх хәзрәт Гарипов алып барды. Беренче чиратта ул мәчет тарихы белән таныштырды.

Тарихтан билгеле булганча, Яңа Кырлай мәчетен авыл кияве Хәкимҗан Ишморатов төзетә. 1911 нче елда ук мәчет салдыру артыннан йөри башлый һәм, ниһаять, иман йорты 1913 нче елда сафка баса. Шунда ук кызлар һәм малайлар өчен мәдрәсәсе дә эшли. Мәчетләрне кырган заманда ул да зыян күрә, Х.Ишморатов Себергә сөргенгә куыла, кәгазь ясау фабрикасы ача. Тик анда да тынычлыкта калмый, озакламый үзен аталар.

- 1936 нчы елда мәчетне ябалар, манарасын кисәләр. Тик ул кайбер урыннардагы кебек клуб, склад итеп файдаланылмый, балаларга белем бирү йорты була, - дип сөйләп китте Вазыйх хәзрәт. - Каюм Гыйлаҗетдинов, Гомәр Яруллин мәчетне янадан торгызу мәсьәләсен күтәреп чыкты. Фарух Мортазин, Даян Шакиров Мәдәният министрлыгына кадәр барып, финанс ягын кайгыртты. Мәчетне сафка бастыруга бөтен авыл халкының өлеше керде. Манарасы да, ае да булды. 2011 нче елда ул яңадан төзекләндерелде. Бу юлы район башлыгы финанс ярдәме күрсәтте. Хәзер күңелләребезгә иман нуры өстәп, көн дә иртән авылда азан тавышы яңгырый.

Мәчет иркен, зур, якты, җылы. Тәүлек буе утырып гыйбадәт кылсаң да була. Мәдрәсә дә эшләп килә. Өлкәннәргә Рәшидә абыстай, балаларга Кәримә һәм Зәйтүнә абыстай дин дәресләре бирә. "Тик балаларны тарту гына кыенрак", - ди Вазыйх хәзрәт.

- Җибәрегез балаларыгызны мәчеткә, килсеннәр, дини белем алсыннар. Дингә килгән кешене авырлыклар да читләтеп уза, бәхетне дә Коръәннән табарга була, - дип, Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең дәгъвәт бүлеге белгече Тимергали хәзрәт Юлдашев вәгазь дә сөйләде.

Арча районының Мөгаллимәләр шурасы җитәкчесе Рая Фәтхуллина Арча хакимияте, мөхтәсибәте исеменнән олы юбилей белән котлап, теләкләрен шигырь юллары аша җиткерде. Арча мәчетеннән килгән Нурлыһодә Хәнәфиева күңелләргә үтеп керердәй матур һәм моңлы итеп мөнәҗәт укыды. Алексеевск районы Югары Татар Майнасы авылыннан бәйрәмгә дип махсус килгән Әмин хәзрәт белән очрашу аеруча кызыклы булды.

- Моннан 52 ел элек Яңа Кырлайга ут кертүдә катнашкан идем мин, - диде ул. - Шул вакыттан күңелгә якын булып кереп калган бу мәчет. Мондый олы юбилейга бармау гөнаһ булыр дип уйладым. Мәчетнең гомере озын булсын, иманлы кешеләр тәрбияләсен иде.

Әмин хәзрәт мәчеткә бүләк, муллага чапан, умартачы буларак күчтәнәчкә бал һәм... бер бидон таң суы алып килгән.

- Бу көннәрдә авылда һәркемнең телендә мәчет, дин. Күпме ризык алып килделәр, әзерләшергә булыштылар! Шулай ук иганәчеләргә дә барлык авыл халкы исеменнән рәхмәт. "Кырлай" агрофирмасы ширкәте (ул мәчетнең коммуналь хезмәтләре өчен дә түләп бара), "Касыйм" ширкәте, "Сафиуллиннар" фермер хуҗалыгы зур ярдәм күрсәтте, - диде Вазыйх хәзрәт.

Мәҗлескә "Кырлай" агрофирмасы җитәкчесе Габделхәй Кәримов, Яңа Кырлай авыл җирлеге башлыгы Газинур Сәфәров килгән иде. "Авылыбыз өлкәннәре һәр изге гамәлебез өчен дога кылып тора. Шуңа эшләребез дә уң безнең, - диде Г.Кәримов. - Аллаһы Тәгалә өлкәннәребезгә озын гомер бирсен, бер гасырлык мәчетебездә азан тавышы тынмасын".

**Гөлсинә ЗӘКИЕВА,**
**"Арча хәбәрләре"**

# КҮҢЕЛЛЕ ЯШИБЕЗ

**"Ашаганнан соң бер тапкыр дога кылган идем, "Улым, син җитешкәнсең икән инде", - диде әти. Бу узган гасырның 80 нче елларының октябрь ае иде. "Тәһарәт ал, намазга бас, минем укыганымны тыңла. Кириллица белән түгел, гарәп хәрефләре белән укырга өйрән", - дип, әти белән әни мине туры юлга бастырды". Азнакай районы имам-мөхтәсибе Әмирҗан хәзрәт Якуповның шулай дип сөйләгәне хәтергә кереп калган. Без аның белән элемтәгә кереп, хәл-әхвәл сорашырга булдык. Хәзер районда нинди эшләр алып барыла икән?**

- Күңелле яңалыгыбыз бар: яңа уку елы Актүбә бистәсендә яңартылып төзекләндерелгән бинада башланып китте. Моңа барыбыз да сөенде. Район башлыгыбыз Марсель Зөфәр улы намазга басты. Ул Корбан бәйрәменә килеп безне тәбрикләде. Актүбә эшчеләр бистәсе бар яктан үскәннән үсә. Бүгенге көндә биредә мәдрәсәдә егермеләп бала белем ала. Моңарчы алар мәчеттә укыды. Аларга "Мөхәммәдия" мәдрәсәсен тәмамлаган мөгаллимәләр дәрес бирә. Мәдрәсәдә ашханә дә бар. Анда дини бәйрәмнәрне дә уздырабыз. Моннан тыш, районыбыздагы һәр мәчеттә дә укулар алып барыла. Азнакай шәһәрендәге Ак мәчет мәдрәсәсендә реконструкция эшләре алып барабыз. Бинаны зурайтабыз. Безнең мөхтәсибәт шунда урнашкан.

Быел районыбызда Корбан бәйрәме бик тә киң күләмдә билгеләп үтелде. Барлыгы 220 баш корбан чалынды. Район башлыгы Марсель Шәйдуллин (ул тумышы белән Әлмәт районы Нәдер авылыннан) дүрт сыер бирде. Алар корбанга чалынып, социаль яклау бүлегеннән алынган исемлек буенча таратылды. Район хакимиятендә эшләүчеләр аны үзләре кешеләргә кертеп йөрде. Республика күләмендә дә эшләребез гөрләп бара, бөртекле культуралар уңышы буенча быел алдынгылыкны бирмәдек.

Өлкәннәр үнкөнлеге барышында да бик зур чаралар үткәрелде. Пенсионерларны ашханәләргә чакырып хөрмәтләделәр, бүләкләр өләштеләр...

Диния нәзарәте Корбан бәйрәме алдыннан үзебезгә дә тәм-томнар тулы пакетлар таратты, яңа гына табадан төшкән "Шура" әлманахын тапшырды. Имамнарга бушлай таратылган әлеге журнал дини эшләрне алып баруда бик зур ярдәмлек вазыйфасын үти. Әйтик, үткән җомгаларда гына хәнәфи мәзһәбенең әһәмияте турында халыкка янә бер кат аңлатып, очрашулар үткәрдек.

***Нияз САБИРҖАНОВ***

# ВАТАННЫ ЯРАТУ – ИМАНДЫР

*Чүпрәле районы Мунчәли авылында Авыл бәйрәме булып узды. Авыл мәчетенең 15 еллыгына багышлап, "Дини җыен", II "Мунчәли укулары" фәнни-гамәли-дини конференция оештырылды. Капиталь төзекләндерүдән соң мәдәният йорты да үз ишекләрен ачты.*

*Дөньяда биш Мунчәли авылы бар икән. Шуларның берсе Пенза өлкәсе Каменка районында урнашкан. Бәйрәмгә Пенза кунаклары да чакырулы иде. Мунчәли укуларында шулай ук танылган галимнәр - филология фәннәре докторы Марсель Әхмәтҗанов, тарих фәннәре кандидаты Рафикъ хәзрәт Насыйров, Рөстәм хәзрәт Ясәвиев һәм башкалар катнашты. Татарстан мөфтие урынбасары Нияз хәзрәт Сабиров авыл халкына һәм килгән кунакларга хаҗ сәфәрендә алган тәэсирләре турында сөйләде.*

*Мунчәли укуларының әһәмияте нидә? Оештыручылар ни өчен аның нәкъ менә дини юнәлешле булуына басым ясарга тырыша? Әнә шул сорауларга җавап итеп, түбәндәге язманы урнаштырабыз.*

**Редакциядән**

Соңгы елларда тарихыбызны, дин өлкәсендәге күренекле галимнәребезнең тормышын өйрәнүгә, төбәктән чыккан шәхесләребезне, алар яшәгән урыннарны барлауга зур игътибар бирелә. Истәлекле кичәләр, фәнни-гамәли конференцияләр, укулар оештырыла. Шул исәптән без Мунчәли авылында инде икенче тапкыр "Мунчәли укулары" дигән фәнни-гамәли-дини конференция оештырдык. Үткән ел аның беренчесе мәшһүр татар драматургы Туфан ага Миңнуллинның вафатыннан соң, аның туган көнендә мемориаль такта ачканда үткәрелгән иде. Анда катнашкан галимнәр, дин әһелләре бу чараны югары бәяләде һәм һәр елны үткәрергә кирәк дигән карарга килende. Динебезне, милләтебезне һәм мәдәниятебезне үстерү үрнәкләрен күрсәтү буларак, Мунчәли укуларының дәрәҗәсе елдан-ел күтәрелә, масштабы киңәя бара.

Быел ул "Авыл халкының әхлагын һәм дөньяга карашын тәрбияләүдә дини кыйммәтләрнең мөһимлеге" дигән темага багышланды. Чарага бик күп кунаклар мәртәбәле шәхесләр, галимнәр, дин әһелләре җыелган иде.

Бүгенге көндә халкыбызның әхлагын тәрбияләүдә дини кыйммәтләргә зур игътибар бирелә. Мәчетләребездә динне өйрәнү дәресләре алып барыла. Ният-максатыбыз халкыбызның үткән тарихын белүче, аның асыл сыйфатларын дәвам итүче һәм саклаучы иманлы, җәмгыятебезгә файдалы, зыялы, мәгърифәтле, югары әхлаклы халкыбыз варисларын тәрбияләү.

Безнең Мунчәли авылы элек-электән укымышлы, дини авыл булган. Республикабызга бик күп танылган шәхесләр биргән ул. Советлар Союзы Герое Нурулла Фазлаев, Социалистик Хезмәт Герое Абдулла Сабирҗанов, Татарстанның атказанган укытучысы Маһруй Якупова, галим, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе Нурмөхәммәт Хисамов, Россия Федерациясенең атказанган юристы, Татарстан Республикасының элеккеге прокуроры, Конституция суды рәисе Сәйфихан Нәфиев, артистлардан Венера Шәрипова, Алсу Гайнуллина, Алсу Әбелханова, шагыйрь Рәмис Әймәт... Барлый башласак, алар бик күп. Мунчәлидә үсеп чыккан йөздән артык авылдашыбыз бүгенге көндә республикабызда һәм Россиядә төрле оешма һәм предприятиеләрне җитәкли.

Халкыбыз: "Үгет-нәсыйхәт - бездән, әдәп белү - үзеңнән", - дип бик дөрес әйткән. Иң асыл рухый-әхлакый кыйммәтләр, дөрес яшәү кануннары ислам динендә һәм татар авылының тәрбия тәҗрибәсендә тупланган. Шул изге мирасны - бәһасез кыйммәтләрне үзләштереп, үзенең рухый тормышын, әдәп-әхлагын, чынбарлыкка карашын һәм гамәлләрен уңай якка үзгәртсә, үзенең яшәү рәвеше, тормыш итү кагыйдәләре итеп кабул итә алса, ул яшь кеше киләчәктә үзенә дә гаиләсенә дә, әйләнә-тирәдәгеләргә дә иманлы, бәрәкәтле яшәү үрнәкләре күрсәтәчәк.

Соңгы елларда татар авылларында бигрәк тә яшьләр арасында эчүчелек, җенси азгынлык, җинаятьчелек чәчәк аткан чорда дөрес тәрбия бирү дәрәҗәсе түбәнәя бара. Вакытында дөрес тәрбия бирмәсәк, бала тормышта үз юлын тапмаячак, аек акыл белән акны карадан аерып, дөрес итеп тормыш алып бара алмаячак. Моның өчен, әлбәттә, дини кыйммәтләргә таянган тәрбия кирәк.

Тормышыбыздагы сабырлык, ярдәмләшү, күркәм мөгамәлә, олыларны, әти-әниләрне хөрмәтләү, туган җиреңне, Ватаныңны сөю кебек сыйфатлар - болар барысы да динебезнең нигезен тәшкил итә. Пәйгәмбәребез (с. г. в.) бер хәдисендә: "Ватанны ярату ул - имандыр", - дигән. Чын мәгънәсендә иманы булган кеше генә Ватанын, туган җирен, туган нигезен яратуның асылын аңлый ала. Дини кыйммәтләрнең иң кыйммәтлесе ул - әхлактыр. Яшьләребезнең әхлагын һәм дөньяга карашын тәрбияләү белән генә без авылларыбызның киләчә-

***(Ахыры 8 нче биттә.)***

# САБАНЫҢ ҖАМИГЪ МӘЧЕТЕН КЕМ ТӨЗЕТКӘН?

...Күпме куерса да вакыйгалар,
Җирдә әле - Иман,
Күктә Ай бар!

*Мөдәррис Әгъләм*

**Әйе, күптән ачыклык кертелергә тиешле сорау иде бу, чөнки борынгы мәгълүматлар төрлечә теркәлгән булып чыкты. Мәсәлән, авторлары Радик Салихов һәм Рамил Хәйретдинов булган "Татар халкының тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре" дигән китапта мондый юллар бар: "Байлар Сабасында рәсми теркәлгән мәхәллә 1797 нче елда барлыкка килгән. Шул ук вакытта Монасыйб бине Габделхалик акчасына мәчет төзелгән (сүз хәзерге мәчеткә кадәр салынганы турында бара - Т.Н.). 1841 нче елда Казанның беренче гильдия сәүдәгәре Габделкәрим Габдерәшит улы Юнысов (1859 нчы елда вафат) беренче мәхәлләнең хәзер дә сакланган ике катлы таш мәчетен салдырды..." (Байлар Сабасының аксакаллары, үзләренә буыннан-буынга ирешкән хәбәрләргә таянып, бу мәчетне 1835-1840 нчы еллар тирәсендә Оренбург сәүдәгәре Габдерәшит салдырган, дип тә сөйләгәннәр).**

1841 нче елгы мәчет төзелешенең кырык биш меңгә төшкәне дә әйтелә. Гыйбадәтханә йортын салдыручы, Байлар Сабасы киләчәктә кала булырга тиеш, ди һәм мәчетнең проектын Петербург архитекторыннан сыздыра. Монысы дөрес тә булырга мөмкин, чөнки хәзерге җәяүлеләр урамының теге башыннан - мәктәп яныннан карасаң, мәчет бинасының нәкъ шул урамга турылап урнаштырылуына игътибар итәсең. Санк-Петербург урамнары да шул рәвешле бит...

Саба мәчетен Габделкәрим Габдерәшит улы салдырган дигән мәгълүматларга таянып, без өлкән яшьтәге әдип Мәгъсум ага Хуҗин белән "Яшә, Саба-Йорт!" китабындагы "Манарада ай балкый" дигән бүлектә берничә мәртәбә, мәчетне Габделкәрим Габдерәшит улы төзеткән, дип биргәнбез. Без генә түгел, Саба җамигъ мәчете хәзрәтләре дә моңарчы шушы исемне кулланып килде. Ә менә мәшһүр галим, күренекле тарихчы-мәгърифәтче һәм фәлсәфәче Шиһабетдин Мәрҗани "Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар" ("Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр", бу хезмәтнең беренче кисәге матбугатта ике тапкыр - 1885 нче һәм 1897 нче елларда, ә икенче кисәге 1900 нчы елда басылып чыга) дигән китабында болай дип язган булган: "...Элек Саба авылында фәкать ике мәчет булган. Хәзерге көндә дүрт мәчет бар. Шул авылда булган янгыннан соң 1257 нче (1841) елның азагында Казан сәүдәгәре Габдерәшит бине Габделкәрим бине Мөхәммәтрәхим бине Юныс мелла Габделгалләм имамлыгы вакытында яңа таш мәчетне төзетте... (Игътибар итсәгез, бу җөмләдә өч "бине" булганлыктан, аларның кайсы үз исеме, кайсы атасыныкы икәнен беренче карашка белеп тә булмый). Ул (мәчет төзеткән Габдерәшит була инде - Т.Н.) 1276 нчы (1859) елда вафат булды. Җеназасын мелла Шиһабетдин бине Фәхретдин укып, Казандагы яңа каберлектә җирләнде. Әхмәт, Мөхәммәтрәхим һәм Гали исемле угыллары калды". Бу исемнәргә язма ахырында тагын бер әйләнеп кайтырбыз әле.

...2012 нче елның декабрендә булып узган Бөтендөнья татар конгрессының V корылтае делегатлары арасында Татарстаныбызның Казахстан Республикасындагы тулы вәкаләтле вәкиле урынбасары, Сабада тукыма фабрикасы тоткан Аблаковлар нәселен дәвам итүче Рафаил Гәрәй улы Аблакова (аларның бабалары 1890 нчы елда Казахстанга килеп урнаша, бу вакытта аның әтисе Гәрәйгә 9 яшь кенә була) бар иде. Ул алга таба үзләренең фамилиясен дөресләп язарга кушты. "Аблаков түгел", - диде. Рафаил ага бу юлларның авторына нәселе белән бәйле истәлекләр дә калдырды. Аларның берсендә: "Из воспоминаний о Казанском купце (меценате) 1-й гильдии Юнусова: его сын взял в жены дочь Бикчантая Аблакова из Богатых Сабов, который построил таш мечеть", - дигән юллар бар.

Күргәнегезчә, бу зманың башында ук өч-дүрт төрле тарихый чыганак китерелде. Шуларны күптән гомумиләштерергә кирәк иде безгә. Әлеге мөмкинлек уйламаганда-көтмәгәндә килеп туды.

...Сатыш мәдрәсәсе бинасы яңартылу уңаеннан кайбер мәгълүматларны ачыклау нияте белән Туган якны өйрәнү музеена кергәч, аның җитәкчесе Резеда Сөнгатова миңа "Казань" журналында (2004 нче ел, №8, 9) басылган бер тарихый очеркның күчермәсен бирде. "Из жизни купцов меценатов Юнусовых" дип исемләнгән иде ул. Әлеге язма Сабаның Бикчәнтәй Аблаков кызы Җәмиләгә өйләнгән Габделкәрим Юнысов турында икән. Аны оныклары Р.Юнысов һәм Д.Зөбәиров әзерләгән булган. Татарчадан русчага күренекле әдәбият галиме Энгель Нигъмәтуллин тәрҗемә иткән.

...Мөхәммәтрәхим Юнысов Казанга Балтач районының Кариле авылыннан килеп урнаша. Аларның эшмәкәрлекләренең биш сумга саткан шалканнан башланып китүе дә искәртелә. Тора-бара Мөхәммәтрәхим тире эшкәртү, күн эшләнмәләр заводлары тота торган зур сәүдәгәргә һәм меценатка әйләнә. 1785 нче елда ук ул иң беренчеләрдән "Казанның мактаулы гражданины" исеменә лаек була. Җәмәгать эшләрендә катнаша. Татар ратушасын җитәкли. Мөхәммәтрәхимнең ике улы - Габделкәрим белән Габидулла һәм кызлары була. Егетләр дә әтиләренең эшен дәвам итәләр. Мәскәү һәм Архангельск кебек шәһәрләрнең байлары белән сәүдә алып баралар. "Мактаулы гражданин" исемен алып, хәрби хезмәттән котылып калалар. Саба кияве Габделкәрим дә торабара җирле татар җәмәгатьчелегенең башлыгына әйләнә. Меценатлык белән дә шөгыльләнүләрен дәвам итәләр Юнысовлар. 1830 нчы елда ваба (холера) эпидемиясе чыккач, ике катлы хастаханә дә салалар, мәчетләр төзиләр. Шулай ук үзләренең типографияләрендә дини китаплар бастырып, халыкка бушлай тараталар. Менә шундый юмартлыклары өчен Габделкәрим Юнысов ике алтын медальгә лаек була. Гомумән, бик күп игелекле гамәлләр кылалар алар. Менә бит нинди игелекле җаннар булганнар.

Саба кияве Габделкәрим 1821 нче елда бакыйлыкка күчә (шулай булгач, ул 1841 нче елгы мәчетебезне берничек тә төзетә алмый. Өч яшьлек улы Габдерәшит (мәчет салдырасы кешебез - Т.Н.) атасыз кала. Аны әтисенең бертуган энесе Габидулла абыйсы тәрбияләп үстерә һәм балигъ булгач, әтисе Габделкәримнең улына тиешле байлыгын бүлеп бирә. Габдерәшит күренекле Казан сәүдәгәрләре һәм эшмәкәрләре, дин һәм җәмәгать эшлеклеләре Апанаевлар нәселеннән Хәсән Апанаевның Маһитап исемле кызына өйләнә. Аларның Әхмәтгәрәй, Мөхәммәтрәхим, Мөхәммәтгали исемле уллары һәм Камәрбану, Фәхрибану, Зөһрәбану исемле кызлары була. Маһитап яшьли бакыйлыкка күчә. Габдерәшит икенче җәмәгате итеп Байлар Сабасы мулласы Габделгалләм хәзрәтнең Ганифә исемле кызын ала. Аларның уртак балалары туа. Аңа Маһруй дип исем кушалар.



*Габдерәшит мәчетенә яңадан ясалган манараның айлы өлеше. Н.Дәүләтов фотосы.*

Менә шулай итеп, Габдерәшит Габделкәрим улы Юнысов 1841 нче елда әнисе Җәмиләнең туган авылына бүләк итеп таш мәчет салдырган булып чыга. Бу вакытта Шиһабетдин Мәрҗани китабында язылганча, әлеге мәхәлләгә чыгышы белән Олы Шыңар авылыннан булган Габделгалләм хәзрәт имамлык итә, алар тыгыз мөгамәләдә булып, тора-бара туганлашалар, хәзрәт газиз кызын тол калган Габдерәшиткә кияүгә бирә. Язмыш кушуы буенча, Габдерәшитнең әтисе Габделкәрим генә түгел, ул үзе дә Байлар Сабасы киявенә әйләнә. Безгә тарихый һәйкәл - гыйбадәт кыла торган Аллаһ йорты салып калдырган Габдерәшит нибары 42 яшендә, 1859 нчы елда вафат була.

Ә хәзер инде язмабыз башындарак бирелгән Шиһабетдин Мәрҗани китабындагы мәгълүматларны "Казань" журналындагысы белән тәңгәлләштерик. "Казан сәүдәгәре Габдерәшит бине (үз исеме - Т.Н.) Габделкәрим бине (әтисенең исеме) Мөхәммәтрәхим бине (бабасының исеме) Юныс (нәселләренең фамилияләре) мелла Габделгалләм (Саба мулласы) имамлыгы вакытында яңа таш мәчетне төзетте... Ул 1276 нчы (1859) елда вафат булды. Әхмәд, Мөхәммәтрәхим һәм Гали исемле угыллары калды (монда Әхмәд белән Галинең исемнәре кыскартылган, журналда Әхмәтгәрәй, Мөхәммәтгали дип мулла кушканча бирелгән). Димәк, шуның белән Байлар Сабасына бүген дә иман нуры чәчеп торучы мәчетнең кем салдырганы ачыкланды, дип нокта куярга мөмкиндер. Бу язманың авторы әлеге мәгълүматлар белән Өлкәннәр клубы әгъзаларын, шулай ук Саба җамигъ мәчетенә җомга намазына йөрүчеләрне дә таныштырды һәм Юнысовларның шәҗәрәләре (югарыда китерелгән аңлатмалар белән) мәчетнең беренче катына ясатып кую өчен хәзерге имам-хатыйбыбыз Илдар хаҗи Яхъяга тапшырылды.

...Менә шундый бай тарихлы мәчетебез байтак еллар елап-сыкрап, рәнҗеп утырган иде. 1930 нчы елда авылның "башы", ягъни мәчет манарасы киселгәннән соң, аның беренче каты клуб, икенчесе КПСС райкомының партия кабинеты, китапханә итеп файдаланылганын күпләр хәтерлиләрдер. Мәчетебезнең кирпеч гөмбәзе дә булган. Аны илленче елларда, җылыту өчен утын күп кирәк дигән сылтау белән сүттергәннәр. Байлар Сабасы өстенә урман аварга торган хәлдә мондый нәрсә эшләү өчен үз халкыңның тарихын-байлыгын хөрмәт итмәү кирәктер!..

Узган гасырның туксанынчы еллары уртасында район белән Фәрит Гыйльметдин улы Гыйльмиев җитәкчелек иткән чорда, гасыр ярымлык тарихы булган иман йортыбыз өр-яңадан реставрацияләнде һәм 1995 нче елның 6 нчы октябрендә җомга көнне, манарасы күтәрелеп, мәчет дин тотучыларга кайтарылды. Соңгы ун ел эчендә хәзерге хакимият башлыгыбыз Рәис Нургали улы Миңнеханов ике тапкыр капиталь ремонт ясатты. Бинаның ишегалдына брусчаткалар җәйдерде, манарага һәм диварларга зәвыклы электр лампалары куйдырды. Әнә шул яктылык нурында хәзер кичләрен һәм төннәрен дә биек манарада горур ай балкый. Яңа манараны "Сельхозтехника" акционерлык җәмгыяте уңганнары ясады. Мәчетне Сабадагы 159 нчы ПМК төзүчеләре яңартты. Гомумән, бу изге эшкә райондагы бик күп хезмәт коллективларының, аерым кешеләрнең өлеше керде.

Мәчетне реставрацияли башлагач:"Искегә тисәң - исең китә, күрше районнар үзәкләрендәге кебек яңаны саласы иде", - дип сөйләнеп йөрүчеләр дә булды, билгеле. Юк. Алай түгел шул! 2016 нчы елда үзенең 175 еллыгын каршылаячак җамигъ мәчебез безгә борынгылыгы, бабаларыбызның тарихый байлыгы - ядкәре буларак кадерле бит! Хәзер инде ул, егерме елга якын еламый-сыкрамый, гел елмаеп кына тора кебек...

Бу язма ахырында мәдрәсәләребез турында бик кыскача гына тукталып китмәсәк, дөрес булып бетмәс. Һәр мәхәллә каршында дин сабагы бирә торган укыту йортлары булган. Без сүз алып бара торган беренче мәхәлләнең мәдрәсәсе 2013 елның 13 июнендә сүтелгән советлар йорты (соңыннан редакция һәм типография урнашкан иде бирегә) урынында булган. Мәдрәсә ябылгач, ул бинаны балалар бакчасы итеп файдаланганнар. Байлар Сабасы авылында туып үскән Гөлбикә апа Ногманова үзенең шушы бакчада тәрбияләнүен әйткән иде.

Узган гасыр башында, төгәлрәге 1902 нче елда бу мәхәлләдә 238 ир-ат, шулардан 61 йорт хуҗасы исәптә торган. Югарыда телгә алынган мәдрәсәдә 48 малай, 37 кыз укыган.

Иске зират урамының (хәзерге Гали Закиров урамы) теге башындарак - "Сельхозхимия" берләшмәсе салдырган ике катлы 44 нче йорт урынындагы икенче мәхәллә мәчете мәдрәсәсендә 18 малай һәм 32 кыз укыган. XX йөз башында мәхәлләдә 257 ир-ат мөселман (86 йорт хуҗасы) исәптә торган. Сабаның үзендәге һәм авыллардагы мәдрәсәләрдә укымышлы хәзрәтләр, дин белгечләре сабак биргән. Шиһабетдин Мәрҗанинең без телгә алган хезмәтләренә күз салсак, анда мелла Мортаза бине Котлыгыш әс-Симети, мелла Җарулла бине әс-Сатыши, мелла Сибгатулла бине Мөхәммәт бине Тимер әс-Сатыши, мелла Сәлим бине Габдерәхим әс-Сабавый, мелла Мөхәммәд Хуҗашәех бине Юллыйк шәйх әс-Сабавый, мелла Сәйфетдин бине Әбүбәкер бине Сәлим әс-Шыңарый кебек дин әһелләре телгә алына.

Гомумән, Саба ягы элек-электән дин, мәгърифәт, шигърият үзәге булган. Бу фикерне раслау өчен Байлар Сабасының үзендә туган, Курса, Мәчкәрә, Бохара мәдрәсәләрендә укып, җырларда җырлана торган Наласа авылында муллалык иткәннән соң, Мисырга китеп, Әл-Әзһәр университетында фарсы теле укыткан Кавалетдин Болгари (Мөхәммәдәмин бине Сәйфулла әс-Сабавый) исемен әйтү дә җитәдер. Ул шагыйрь дә була, 1833 елда бакыйлыкка күчә һәм Каһирә зиратында җирләнә. Мондый мисалларны тагын да дәвам итеп булыр иде...

**Тәлгат НӘҖМИЕВ,**
**Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре**

# БҮГЕНГЕ КӨННӘРНЕҢ ТӨП ЯЛГЫШЫ

**Бүгенге көн кешеләренең төп ялгыш фикере дәһрилек (атеизм) түгел, чөнки чын дәһриләр калмады да диярлек инде. Хәзер күп кешеләр, дөньяга карашның агностицизм дип аталган бер агымы тарафдарлары. Алар Аллаһка күңелләре белән ышаналар, ләкин, алар фикере буенча, "Аллаһ кем Ул?" һәм "Ул безнең ни эшләвебезне тели?" дигән сорауларга җавап билгеле түгел. Кешеләр мондый инануларны Аллаһы Тәгаләнең күрсәтмәләре, таләп һәм тыюлары белән үз тормышларын авырайтмас өчен үзләре сайлап ала. Күңелдән Аллаһка ышанып, дин кагыйдәләре буенча берни дә үтәмичә яшәргә була, дип уйлау - бүгенге көн кешеләренең төп ялгышы.**

Раббыбыз безне ни өчендер яраткан икән, Ул ниндидер бер максатны күздә тоткан һәм бездән ни дә булса таләп итәргә хокуклы. Ул бездән ниндидер гамәлләрне башкаруны, ә икенче бер гамәлләр башкарудан тыелубызны һәм шуның өчен тиешле әҗерен алуыбызны тели. Ә алда китерелгән позиция - дөньявилыкка баткан, Раббыбыз алдындагы үз бурычларын башкару турында исләренә төшерергә теләмәгән кешеләрнеке. Урта гасырларда һәм борынгы заманда кешеләрнең тормышы бик авыр булган һәм алар Аллаһка ихтыяҗларын гел тоеп яшәгән. Алар өчен Аллаһы Тәгаләнең бездән ни таләп итүен сорау - нормаль күренеш булган. Ә хәзер кешеләр дөньявилык мәнфәгатьләрен кайгыртуга шулкадәр чумганнар һәм алар шуны аңлый алмыйлар: ни өчен ниндидер бер гамәлне эшләргә ярый, ә икенче берсен эшләргә ярамый һәм ни өчен билгеле бер дин тарафдары булырга һәм аның кагыйдәләрен үтәп барырга кирәк.

Әгәр дә кеше: "Мин үземә ислам динен сайлап алдым, ә башка бер кеше үзенә башка бер дин, башка бер иман сайлап алырга мөмкин, аның өчен ниндидер башка иман - хак иман, башка дин - хак дин булачак һәм бу кеше дә үзенчә хаклы булачак", - дип уйлый икән, бу - көферлек, ягъни имансызлык була. Андый фикер йөртүләр бик киң таралган. Хәзер хакыйкатьнең күп төрле булуы турында, кешенең, янәсе, ул ни тели, шуны эшләргә хокукы барлыгы турында бик күп сөйлиләр. Тик бу вакытта яхшы кеше булып калырга, Аллаһка үзенчә ышанырга, башка беркемне дә җәберләмәскә генә кирәк икән. Шул чагында ахирәттә аның өчен барысы да яхшы буласы икән.

Экуменизм дип аталган хәрәкәт тә бар, бу хәрәкәт бар диннәрне дә берләштерү ягында, алар, бар диннәр дә бер үк әйбергә - яхшылыкка өндиләр, шуңа күрә дә, аларны берләштерергә кирәк, диннәр арасындагы аермалар зарарлы, ул аермалар төрле ызгышлар китереп чыгара, дип раслыйлар. Тыштан караган вакытта мөселман булып күренгән (традицион мөселман киеме, чалма киеп йөрүче) кайбер кешеләр аларның конференцияләренә дә йөри.

Үзләрен мөфти дип атап йөреп тә, яһүдиләр дә, христианнар да җәннәткә эләгер, алар безнең туганнарыбыз, алар бер Илаһка табынучылар, дип уйлаучылар да бар. Безнең Пәйгамбәребезне (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булса иде) эпилептик, я акылдан язган, я ялган пәйгамбәр дип атаган кешеләр ничек итеп тәүхид тарафдарлары була алсыннар ди? Ә Мөхәммәд пәйгамбәрне (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булса иде) христиан һәм яһүдиләр нәкъ менә шулай итеп тасвир итәләр дә бит инде. Безнең Пәйгамбәребезне (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булса иде) авыру яки ялган пәйгамбәр дип атаучылар ничек җәннәттә булырга мөмкин? Аны ялган пәйгамбәр дип атаучылар Мөхәммәд (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булса иде) белән бергә бер урында берничек тә була алмый.

Андый кешеләр бер нәрсәне аңлап бетерми: Аллаһ бездән таләп иткән төп әйбер - безнең Аның турында хак фикердә булуыбыз, Аның балалары, илаһлыкта иптәшләре, кимчелекләре булмавына инануыбыз, Ул Үзе Үзен сыйфатлаганча Аңа иман китерүебез, Аның пәйгамбәрләренә, шул исәптән Аның соңгы пәйгамбәренә (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булса иде) иман китерүебез. Аллаһы Тәгаләнең ихтыяры - менә шул була да. Ә калганнары, әхлак нормалары, хәләл һәм хәрәм төшенчәләре, болар барысы да - фуруг, диннең эчке тармаклары. Барысының да нигезе - иман, хак дингә ышану. Бу хәрәкәтләрдә катнашучы кешеләр киресенчә исәпли: әхлак - барысының да нигезе, ә иманны һәркем үзенә үзе уйлап таба.

Алар, Аллаһ кешеләргә вәхи иңдерми, ә кешеләр үзләренә үзләре диннәр уйлап таба, дип ышаналар. Шуңа күрә дә, алар фикеренчә, булган диннәрне бер-берсенә кушып, аларның ниндидер бер арифметик уртасын исәпләп чыгаруда бернинди дә начарлык юк. Безнең аңлавыбызча һәм бердәнбер дөрес фикер буенча, дин ул - Раббыбызның соңгы Пәйгамбәре (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булса иде) аша безгә җиткерелгән Аның хак сүзенә ышану вә буйсыну. Исламнан башка бер генә дин дә безнең тарафтан кабул ителми. Бершиксез инану - ул безнең иманыбыз, кем исламны кабул итми - кяферләр, имансызлар, мәңгелеккә Җәһәннәм утына баручылар.

**Әбу Али әл-ӘШГАРИ**

# "ХИЗБҮТ-ТӘХРИР" – АДАШКАН ФИРКА

**Соңгы елларда Россиядә "Хизбүт-тәхрир әл-ислами" дип аталган яңа дини хәрәкәт тарала башлады. Бу дини төркемнең юлы гасырлар дәвамында илебез җирендә яшәгән мөселманнарның дини карашларына, гамәл тәҗрибәләренә туры киләме? Аларның фикерләрен кабул итә алабызмы? Әлеге язмада шушы сорауларга җавап бирергә тырышырбыз, иншә Аллаһ.**

"Хизбүт-тәхрир" ул - адашкан фирка, аларның карашлары һәм гамәлләре турыдан-туры Коръәнгә, Сөннәткә һәм мәзһәбкә каршы килә. "Хизбүт-тәхрир" агымына нигез салучыларның башлыгы - Тәкыййуддин ән-Нәбһәни. Ул 1909 нчы елда Фәләстыйн җирендәге Иҗзим авылында туа. Тәкыййуддин ән-Нәбһәни яшьтән үк Коръәнне күңелдән өйрәнә, дини гыйлемне шушы өлкәдәге шәйх-остазлардан ала, аннан соң, белемен арттыру нияте белән, мәшһүр ислам уку йортында - әл-Әзһәр университетында укый.

1953 нче елда ул Иордания (Үрдүн) җирендә үзенең яңа җәмәгатен оештыра, җәмәгатьнең төп юнәлеше ислам хәлифәлеген төзүгә, аны булдыруга юнәлгән була, ләкин хөкүмәт тарафыннан аның карашлары хупланмый: Тәкыййудин ән-Нәбһәнине Иордания дәүләтеннән куып җибәрәләр. 1977 нче елда ул вафат була.

Һәрбер дини юнәлешнең нигезе булырга тиеш. Безнең нигезебез (хак ислам дине) өч әйбердән гыйбарәт: Коръән, Сөннәт һәм мәзһәб. Хизбиләр исә - Коръәнгә, Сөннәткә һәм мәзһәбкә каршы килүчеләр, башкача әйткәндә, алар үз нәфесләренә ияреп, наданлык чокырына баткан кешеләр. Аллаһы Тәгалә "Ниса (Хатыннар)" сүрәсенең 115 нче аятендә болай ди:

وَمَن يُشَاقِقِ الرَّسُولَ مِن بَعْدِ مَا تَبَيَّنَ لَهُ الْهُدَى وَيَتَّبِعْ غَيْرَ سَبِيلِ الْمُؤْمِنِينَ نُوَلِّهِ مَا تَوَلَّى وَنُصْلِهِ جَهَنَّمَ وَسَاءَتْ
مَصِيراً

*"Әгәр кем дә кем тугры юлны (исламны) табып та, Рәсүлгә (фикере, сүзе яки гамәле белән) каршы килеп, хак мөселманнар юлына (сәхабәләр, табигыйннар юлына) иярмәсә, Без аны үзе теләгән юлдан җибәрербез, җәһәннәмгә кертербез. Аһ, бик тә хәтәр ул җәһәннәм".*

Бу аять ислам гакыйдәсендә иң әһәмиятле хөкемнәрдән санала. Аятьнең мәгънәсенә игътибар итик әле: Аллаһ Раббыбыз аятьтә иярү асылын төгәл аңлата. Беренчедән, иярү - Аллаһ Китабына булырга тиешле; икенчедән, иярү - Аллаһның рәсүле Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәссәламгә тиешле һәм иң әһәмиятлесе - дини гакыйдәбез (карашларыбыз) әһле сөннәт вәл җәмәгать мөселманнарына, ягъни иң әүвәл сәхабәләргә, аннан соң табигыйннарга, аннары имам Әбү Хәнифә, имам Әбү Мансур Мәтуриди, имам Мөхәммәд (Аллаһ аларны үз рәхмәтеннән аермаса иде) кебек танылган галимнәребезгә туры килергә тиеш.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вәссәламнең сәхабәсе Ирбад ибнее Сария (Аллаһ аннан разый булса иде) риваять иткән: "Бер көнне Аллаһ илчесе салләллаһу галәйһи вәссәлам безне бик нык вәгазьләде, аны тыңлаганда күңелләребез тетрәнде һәм күзләребездән яшьләр акты. Без: "Син безнең белән саубуллашасың кебек, ий Аллаһ илчесе, безгә васыять-киңәшләреңне бирсәң иде", - дидек. Рәсүл Әкрам салләллаһу галәйһи вәссәлам болай диде: *"Аллаһтан чын курку белән курыгыз, сезнең өчен куелган (мөселман патшаларына, әмирләргә, голәмаларга, мөфтигә, казыйларга) итагатьле булыгыз дип васыять итәм. Хәтта, сезнең өчен патша буларак, бер мескен хәбәшә колы (Эфиопиянең кара тәнле колы) куелса, аңа да итагатьле булыгыз. Дөреслектә, кем миннән соң яши, ул күп низаглар, ихтиляфлар күрер һәм шул вакытка туры килгән кешегә минем сөннәтемә һәм тугры хәлифәләрнең (сәхабәләремнең) сөннәтенә ябышу тиеш булыр. Шушы сөннәткә тешләрегез белән ябышыгыз һәм бидгать гамәлләрдән ерак булыгыз, чөнки бидгатьләр - адашу ул"* (Әбү Дауд, Тирмизи).

Әгәр хизбиләрнең юлына карасак, алар югарыда әйтелгән аятькә, хәдискә тулысынча хилафлык китерә, чөнки иярү мәсьәләсендә мәзһәбкә карамыйлар һәм динне әһле сөннәт вәл җәмәгать аңлаганча аңламыйлар, хөрмәтле сәләфләребез (беренче гасыр галимнәре, танылган мөхәддисләр) әсәрләренә игътибар итмичә, динне үз белдеклелекләре белән аңлыйлар.

Алар, сахих (дөрес) хәдисләрне шикле дип, шәргый чыганакларны кабул итми. Хизбиләр хәлифәлек төзергә омтыла, бу ашкыну наданлыктан килеп чыга. Алар фикеренчә, хәлифәлек булмаганда шәригатьнең шактый өлеше тормышта үтәлмәсә дә ярый. Моңа рөхсәт барлыгын искәртәләр, шуңа күрә аларның ирләре җәмәгать белән намаз укымый, алар тәмәке тартырга, җенси мөнәсәбәт, якынлык турында фильмнар карарга (ул хәрәм гамәлләрдән санала) рөхсәт итә. Хатыннарына кысан, тар, гаурәтләре күренеп торган киемнәр киеп йөрергә рөхсәт итәләр, Аллаһ сакласын!

Данлыклы галимнәребез хәлифәлек мәсьәләсе турында: "Ислам дәүләтен иң әүвәл күңелдә, калебтә торгызырга кирәк, калебтә торгызылган ислам дәүләте җирдә дә торгызылачак", - дип әйткән. Нинди тирән мәгънәле сүзләр! Чыннан да, хизбиләргә карасак, аларның ислам дәүләте телдә генә, калебләрендә исә ислам дәүләте юк.

Шулай ук, хизбиләр иман шартларының кайбер өлешләренә дә каршы килә. Алар кабер газабын инкяр итә, аңа ышанмый. Кабер газабы хакында хәдисләрне бер сәхабә генә риваять иткән дип әйтәләр, шуңа күрә андый хәдисләрдә ялган сүз, уйдырмалар, өстәмә сүзләр булырга мөмкин, диләр. Имам Бохари җыентыгындагы шактый хәдисләрне кабул итмиләр, аны кабул итмәүләре бер хәл, хәтта Коръән аятьләренә дә шикләнеп карыйлар. Мисал өчен, Аллаһы Тәгалә Коръәндә "Мөэмин" сүрәсенең 46 нчы аятендә болай ди:

*"Алар (кяферләр, монафикълар) (каберләрендә) Кыямәткә хәтле иртә-кич ут газабына дучар булыр. "Фиргавенгә һәм аның токымына җәзаның иң хәтәрен бирегез" дип, Аллаһ фәрештәләргә әмер бирер".*

Ибне Кәсир, ибне Җәрир, Муҗәһид, Зәйд ибне Әсләм (Аллаһ аларны үз рәхмәтеннән аермаса иде) кебек мәшһүр мөфәссирләр бу аять кабер газабы хакында дип әйткән. Хизбиләр исә бу аятьнең төп асыл мәгънәсен бозып, икенче мәгънәгә әйләндерә.

Кабер газабы турында сахих (дөрес) хәдисләр дә бик күп. Мәсәлән, имам Бохари җыентыгында Гайшәдән (Аллаһ аннан разый булса иде) риваять ителә: "Бервакыт Гайшә янына бер яһүди хатын килеп, аңа болай дип әйткән: *"Аллаһ сине кабер газабыннан сакласын". Шуннан соң Гайшә бу хакта, ягъни кабер газабы турында, Рәсүлуллаһтан сораган. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вәссәлам яһүди хатынның сүзен раслап, хәтта үзе дә кабер газабыннан Аллаһка сыенган"* (Бохари).

Икенче бер хәдисләрдә әйтелгәнчә, үлгән кешеләрнең тәннәре каберләргә җирләнгәч, җаннар үзләренең тәннәре янына - кабат җиргә әйләнеп кайта. Шуннан соң җан янына Мөнкир белән Нәкир исемле ике фәрештә килә. Алар мәеткә торып утырырга куша һәм: "Раббың кем? Динең нинди дин? Пәйгамбәрең кем?" - дигән өч сорау бирә. Иманлы кеше шушы сорауларга дөрес җавап бирә, ә имансызлар бөтенләй җавап бирә

***(Ахыры 8 нче биттә.)***

# "ХИЗБҮТ-ТӘХРИР" – АДАШКАН ФИРКА

*(Ахыры. Башы 7 нче биттә.)*

алмый, моннан соң мәрхүмнәр, нинди җавап бирүләренә һәм гомерләре буена нинди гамәлләр кылуларына карап, савапларга ирешә башлый яисә җәзаларга дучар була. Кабер газабы турында башка бер хәдистә болай дип әйтелгән: *"Кабер ул - буш дөнья түгел. Иманлы бәндә өчен ул - җәннәт бакчаларыннан бер бакча, иман-сыз кеше өчен - җәһәннәм чокырларыннан бер чокыр булачак"* (Тирмизи).

Шулай ук, хизбиләр Мәсих Дәҗҗалның килүен инкяр итә. Мәсих Дәҗҗал хакындагы риваятьләрне кабул итмиләр. Дәҗҗалның барлыкка килүе Кыямәт көненең иң зур ун билгеләренең берсе булып санала. Аның барлыкка килүе кешелек өчен бөек сынау булачак, коткы һәм фетнә чыгарачак. Дәҗҗал гадәттән тыш көчкә ия кеше булачак һәм үзен илаһ дип белдерәчәк. Хәдисләрнең берсендә бу хакта болай дип әйтелгән: *"...Адәм барлыкка китерелгәннән бирле җир йөзендә Дәҗҗал кебек башка коткы булмаган..."*

Шулай ук, хизбиләр Гайсә галәйһиссәламнең кабат килүенә ышанмый. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәлламнең хәдисләрендә әйтелгәнчә, Дәҗҗалның җирдә булырга тиешле вакыты төгәлләнгәннән соң, Аллаһ, аны һәлак итү өчен, җиргә Гайсә галәйһиссәламне төшерәчәк. Гайсә галәйһиссәлам, җиргә иңгәннән соң, Бәйт әл-Мәкъдискә (Иерусалимга) юнәлеп, Дәҗҗалны эзәрлекли башлаячак. Куып җиткәч, аны Бәб Лүдд (Суриядәге тау) тирәсендә үтерәчәк. Мөселманнар, Гайсә галәйһиссәламгә ияреп, Дәҗҗалның гаскәрен җиңеп юк итәчәк. Хизбиләр моңа ышанмый.

Аллаһ Раббыбыз һәммәбезне дә төрле адашулардан сакласа иде. Хак динебезне өйрәнеп, изге гамәлгыйбадәтләр кылып яшәргә насыйп итсә иде!

**Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең дәгъвәт бүлеге**

# ВАТАННЫ ЯРАТУ – ИМАНДЫР

***(Ахыры. Башы 5 нче биттә.)***

ген күз алдына китерә алабыз. Ә бүгенге татар авылы чынлап та ярдәмгә мохтаҗ. Дәүләт ярдәм кулын суза, әлбәттә, әмма авылларны саклап калу өчен ул гына җитми. Монда халыкның да активлыгы сорала. Авылның берәр өстенлекле ягын алып, аны төрле яклап үстерергә, аның әхлакый климатын, халыкның дөньяга карашын үзгәртергә кирәк. Беренче чиратта, авыл халкы үзе активлык күрсәтеп, мөмкинлеге булган хәлле якташларыбыз да аларга килеп кушылса, безнең авылларыбыз киләчәктә тагын да үсеп, чәчәк атачагына ышанам. Гомумән, бар яклап алып барырга: дини укуларны да оештырырга, авыл тарихын да язарга, авыл бәйрәмнәрен дә уздырырга кирәк. Халыкны бергә туплап, кайтмый йөргән якташларны кайтарып, авылга булган карашларын үзгәртә алсак, бергәләп авылны саклап кала алачакбыз.

Бездә бу эш инде башланып китте. Быел гына да якташыбыз мәрхәмәтле, изге җанлы мәртәбәле шәхес, олы йөрәкле ханым Дания Әсхәт кызы Тулованың матди ярдәме белән 1973 нче елда төзелгән мәдәният йорты бинасы, тарихый мирас буларак сакланып, заман таләпләренә туры китереп яңартылды. Моннан тыш Мунчәли урамнарына 3 километрдан артык аралыкка юл күтәреп таш салынды, ике автомобиль күпере, бер җәяүлеләр басмасы төзекләндерелде, су басудан саклау максатыннан авыл аша уза торган Буштерлә елгасы агачлардан чистартылып, ярлары күтәртелде. Зират капкасы яңартылды. Әлбәттә, бу - зур хезмәт, изге эшләр һәм саллы матди ярдәм дигән сүз. Аллаһы Тәгаләнең ярдәме белән киләчәктә дә бу эшләрне дәвам итәрбез дип ышанам.

Ә Мунчәли укуларына әйләнеп кайтып, шуны әйтәсем килә: Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең еллык эш планына кертеп, республикабызның башка районнарыннан да дин әһелләрен чакырып, тагын да зуррак масштабта үткәрәсе иде аны... Форсаттан файдаланып, әлеге чараны оештыруда башлап йөрүчеләрнең берсе булган Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсә директоры Ильяс хәзрәт Җиһаншинга зур рәхмәтебезне җиткерәбез.

***Ильмир ИЗМАЙЛОВ,***
***Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары***

# Урта Пошалым мәчетен бергәләп төзик!

Хөрмәтле авылдашлар, якташлар, милләттәшләр һәм дин кардәшләр! Аллаһы Тәгалә кушып, Татарстан Республикасының Арча районы Урта Пошалым авылында мәчет төзелә. Халыкны, ил төкерсә, күл була, диләр. Әйдәгез, шушы саваплы эшне бергәләп башкарыйк! Күгебездә тагын бер изге ай калыксын!

Изге гамәлдә матди ярдәм кылырга теләүчеләр өчен, мәхәлләнең Россия Саклык банкындагы исәп-хисап счёты номеры: 42307810262165010034/48.

**Корр. счёты номеры: 20202810167000100679.**

Шулай ук, мәчет төзелешенә акчалата ярдәмне авылда (имам-хатыйбка яисә мәхәллә казначеена) калдырып китәргә дә була.

# ИҢ ЯХШЫСЫ – САРЫК КЕБЕК ХАТЫН

**Белеп тор: хатыннар 10 төрле була, аларның һәркайсының холкы билгеле бер җанварның холкына охшаган. Берләре дуңгыз кебек, икенчеләре маймылга охшаган, өченчеләре - эттәй, дүртенчеләре елан төсле, бишенчеләре ишәк кебек, алтынчылары чаянны хәтерләтә, җиденчеләре тычканга охшаган, сигезенчеләре - кошка, тугызынчылары - төлкегә, унынчылары - сарыкка.**



Холкы дуңгызныкы кебек булган хатын-кыз каян да булса азык табып алып корсагын тутыру һәм савыт-саба кырудан башка бер нәрсәне дә яхшы итеп эшли белми. Ул иманга, намаз укуга, ураза тотуга игътибар бирми, үлем көне җитәчәге, Аллаһның вәгъдәләре һәм кисәтүләре, савап һәм гөнаһ, җәза алу, Аллаһ күрсәтмәләре һәм тыюлары турында уйланмый; ул Аллаһ ризалыгын алу һәм аның дәһшәте турында да оныта; балаларын кайгыртмый, тәрбияләми, аларга фәннәрне һәм Коръәнне өйрәтми, шапшак кием киеп йөри һәм аннан яман ис килә.

Холкы маймыл кебек булганы шул: анысын, бары тик үз ахирәтләре каршында кукыраеп, купшыланып, үзен алардан өстен куярга тырышып, сары, кызыл, яшел төсләрдәге матур күлмәкләр киеп, асылташлар, бизәнү әйберләре тагып йөрү, үзен алтын-көмеш белән бизәү генә кызыксындыра. Ул шуның белән ире каршында үзенең тоткан урынын күтәрергә тырыша, гәрчә, бәлки, аның тоткан урыны моннан соң шуның киресенә әйләнсә дә.

Ә холкы этнекедәй хатын-кыз шундый була: ул үз иренә эт кебек ташлана, аңа кычкыра, бәхәсләшә башлый. Иренең акча янчыгы алтын-көмеш белән тулы, өендә җитешлек, барысы да - икмәге дә, җиләк-җимеше дә булса, ул аны яхшы каршы ала, аңа тартыла һәм: "Мин синең өчен җанымны бирергә әзер, Аллаһ синнән разый булсын! Мин синең өчен үләргә әзер!" - ди. Әгәр дә инде эшләр киресенчә торса, алда әйтелгәнчә булмаса, эт кебек ташлана, аны төрлечә кимсетә, җәберли башлый, өйдән куа, фәкыйрьлеге өчен битәрли.

Холкы еланныкына охшаган хатын-кыз үз иренә ягымлы сүзләр сөйли, тик шул вакытта, күп начар әйберне әйтми калып, аннан яшерә һәм чынлыкта, үз ирендә бернинди яхшы як та күрми. Тешләве татлы, тыштан караганда сөйкемле булганга, һәм шул ук вакытта ирен газапларга салганга, ул хатын еланга охшаган да инде.

Ишәк кебек хатын - шул ишәк кебек үзсүзле, кире хатын. Күпер уртасында туктаган ишәкне күпме генә кыйнасаң да, урыныннан кузгалмый бит. Ул да һәрвакыт үз сүзендә кала, үз сүзенең өскә чыгуы белән горурлана.

Ә чаянга охшаганы өй борынча башкалар турында гайбәт сатып, аларга яла ягып йөргән хатын була. Ул башкаларны тыңлый да, шул ишеткәнен яман итеп сөйләп, кешеләр арасында дошманлык һәм ызгыш-талаш тарата. Андый хатын Аллаһтан курыкмый, ул кайда гына булса да чагарга торган чаян кебек. Алар турында Аллаһның рәсүле (с. г. в.): "Гайбәт сөйләгән кеше җәннәткә кермәс", - дигән.

Ә тычкан кебек холыклы хатын - бур хатын, ул иренең акча янчыгыннан акча урлый да, аны күршеләргә кертеп яшереп куя.

Ә кош кебек дигән хатын - көне буе әйләнә-тулгана, ял итәргә вакыт тапмый. Үзе иренә: "Син кая барасың? Мин сиңа кирәкмиммени? Башка берәрсен яратасыңдыр әле, хәзер шунда барасыңдыр. Син минем белән үзеңне гадел тотмыйсың, кызганмыйсың", - дип бәйләнә.

Төлке кебек холыклы хатын ире өйдә вакытта аны тереләй тотып ашый, битәрли, ирен өйдән куа, ире кайтып кергәндә йоклап ята яки авырган булып кылана, аның белән талаша, син мине - авыру хатыныңны берүзен калдырып чыгып киттең, ди.

Холкы сарыкныкы кебек булган хатын - иң мөбарәк, яхшы хатын. Ул сарык кебек юаш, аннан барысына да файда һәм бәрәкәт кенә. Ул диндар, ире, балалары, өйдәге башка кешеләр, күршеләре белән яхшы мөнәсәбәттә, аларга ярдәм итәргә һәрвакыт әзер. Ул бәрәкәте чынлап та күп булган, Аллаһы Тәгаләгә итагатьле хатын.

***Имам Әбу Хәмид әл-Газзалиның "Хакимнәргә үгетләр" китабыннан***

**«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. №11-12 (206-207) чыгарылыш.**
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** № 35424-35425.

**Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя - 3,00 сум.**
**Редакция һәм нәшер итүче адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27. "Дин вә мәгыйшәт" газетасы редакциясе. Язылу индексы - 16046.
***График буенча бу санга 31 октябрь көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә.***
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.

Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан сакланыгыз!**